# Кереш

Шәҗәрә сүзе татар телендә нәсел-ыру тарихы дигән мәгънәдә файдаланыла. Шәҗәрә аркылы кешеләр ата-бабаларының дәвамчысы булуларына төшенгәннәр. Нәсел шәҗәрәсен белү аларда туган илгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә, туганнарга, кардәш-ыруга, күрше-күләнгә хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтеп яшәргә кирәклеген искәртеп торган. Шәҗәрәдә - ил тарихы. Тарих ул – шәхесләр тарихы. Аның тамырлары гаилә тарихына килеп тоташа. Гаилә тарихын туган җир, авыл, мәктәп тарихыннан башка күз алдына китереп булмый. Һәр Кеше үзенең нәсел җебен, гаилә шәҗәрәсен белергә тиеш булган кебек, мәктәп тарихын да белергә тиеш дип саныйбыз без.

Мәктәп – туган җир җылысын бирүче, балачак һәм үсмер еллар истәлеген саклаучы, яшьлекнең хисләрен,беренче серләрен уртаклашучы, киләчәккә - олы юлга аяк бастыручы, озак еллар дәвамында үзенә чакырып, олылап каршы алучы изге йорт ул. Йортның киләчәге бүгенге белән бәйле. Без Ш.Мәрҗәнинең “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк” дигән гыйбарәсен бераз үзгәртеп, “Үз мәктәбенең тарихын белмәгән авылның киләчәге өметсез” дип әйтер идек. Армый-талмый үз укучыларының күңелен туендыручы, үзенең сафлыгы белән куандыручы, тирәнлеге белән сөендерүче, зыялы затлар үстерүче чишмә корымасын, саекмасын өчен, әлбәттә, аның тарихын белү кирәк. Бу тема өйрәнелгән темаларның берсе булса да, елдан ел үзенең актуальлеген ныграк раслый. Шушыларны истә тотып, без Исәнбай мәктәбе укучылары, мәктәбебез елъязмасын төзүне үзебезгә максат итеп куйдык. Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Авылда мәктәп ачылу тарихы.
2. Башлангыч мәктәп – 1917-1931 нче елларда.
3. Җидееллык мәктәп. Мәктәп Бөек Ватан сугышы елларында.
4. Урта мәктәп. Бүгенге көн мәктәбе.

Мәктәбебезнең елъязмасын мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл итеп башкару өчен, без Сарапул, Ижау, Казан архивларында эзләнеп, Исәнбай авылы тарихын язучы Корбангалин Ниязи язмалары, “Туган якны өйрәнү” музеендагы материаллар, авылдашларыбызның истәлек-хатирәләре, вакытлы матбугат язмаларына таяндык. Эшебезне “Туган якны өйрәнү”, “Тамчылар” түгәрәкләре, укучыларның фәнни оешмасы әгъзалары һәм тарих, татар теле һәм әдәбияты, география укытучылары белән берлектә башкардык.

## I бүлек. Башлангыч мәктәп.

### 1.1. Революциягә кадәрге башлангыч мәктәп.

Исәнбай мәктәбенең тарихы - гыйбрәтле зур тарих.

Авылда халык мәгарифе дин әһелләре карамагында булган. XIX гасырда Исәнбай 3 мәхәлләдән торган. Ак, яшел һәм зәңгәр дип исемләнгән мәчетләрдә 4 мулла, 3 мәзин хезмәт куйган. Мәхәллә мәктәпләре балаларга башлангыч белем бирергә тиеш булганнар. Әмма алар бу теләкләренә ирешә алмаганнар. Бу мәктәпләрдә төп дәрес булып дин сабагы саналган. Уку-укыту эшләре гарәп телендә тик ятлауга нигезләнеп алып барылган. Балаларга коръән һәм башка дини әсәрләрдән алынган өзекләр бирелгән. Балалар мәхәллә мәктәпләрен тәмамлаганнар, әмма грамоталы була алмаганнар.

Авылда 1868 нче елда рус - татар училищесы ачыла. Укытучы итеп Минзәлә уезды Семиостров волостеннан Габделмәлик Исхаков җибәрелә. Укыту рус телендә алып барыла, бары тик 4 кенә бала укый, ләкин озак та үтми, мәктәп ябыла. Авылның дин әһелләре – муллалар русча укытуга ифрат каршы торалар. Мәктәпнең гомере кыска була, бары 1 ел. [ 19, 63 ]

Вакыт уза, тарихи шартлар үзгәрә. Авылда Сарапул, Ижау, Алабуга калаларындагы базарларда кибетләр тотып яшәүче Сөендеков, Тутаев, Тукманов шикелле байлар да була. Алар, әлбәттә, үз балаларына, кардәш-ыругларга җәдитчә - заманча белем бирүне өстен санаганнар. 1897 нче елда, ниһаять, Исәнбай авылында "рус-башкорт училищесы" дигән дүртьеллык башлангыч мәктәп ачыла (типтәрләргә тиешле 15 дисәтинә урынына башкорт катламына язылганнарга 40 дисәтинә җир биргәнгә күрә, исәнбайлылар "ут күршеләр" булып теркәлгәннәр). [19, 63] Казанда укытучылар мәктәбен тәмамлаган Насыйбуллин Хәбибулла Фәтхулла улы укытучы булып килә. Төскә-биткә чибәр, мыеклы, килешле гәүдәле, өстенә кара костюм, башына түбәтәй, аякларына кара ботинка кигән, йомшак кына сөйләүче укытучыны авыл халкы бик ошата. Барча малай-шалайны кызыктырып, Хәбибулла Сарапулдан исәнбайлыларның төшенә дә кермәгән ачылмалы парталар, кара такта, глобус һәм тагын әллә никадәрле вак-төяк төяп кайта. Мәктәпнең үзенең бинасы булмый, сәүдәгәр Әхмәтвәли Тютиев йортын файдаланалар (хәзерге вакытта бу урында Сабитов Азат Салихҗан улы йорты).



Беренче елда рус мәктәбендә 8-15 яшьтәге малайлар белем ала башлый. Бу хакта, Корбангалин Ниязи язмаларында бирелгәнчә, шул балаларның берсе Хәлиуллин Хәбибулла болай дип искә ала: *"Әхмәт өендә мәктәп ачылды. Учитель кара түбәтәйдән, пөхтә кәчтүмнән, ялтырап торган кара ботинкадан безне елмаеп каршы алды. Укытучы безне шкулга алып керде. Сарыга буяган идән ялтырап тора. Без күрмәгән – белмәгән сары аяклы кара утыргычлар!.. Без каушап, аптырап калдык. Укытучы безне үзе җайлап утырта башлады... "Минем исемем Хәбибулла, фамилиям Насыйбуллин. Мин сезне укырга, язарга, сөйләшергә өйрәтермен. Сез*

*тырышып укысагыз, мин көчемне, вакытымны кызганмам", - диде. Ул безгә үтә ошады. Аның ягымлы тавышы әле дә колак төбемдә."* [ 7, 59]

Укулар, 24 нче сентябрьдән башланып, 24 нче апрельгә кадәр дәвам итә. Дәресләр - 45, ә тәнәфесләр 15 минут була. Ни үкенеч, малайларның һәммәсе дә дүртьеллык мәктәпне тәмамлап чыга алмый. Кышкы көннәрдә әти-әниләр балаларын мәктәпкә даими йөртсәләр дә, яз җитүгә кайсын "хуҗалыкта эш бар", кайсын "акча юк" дип, сабактан аералар. Кайбер укучылар хәтта хәер һәм ризык теләнеп йөрергә дә мәҗбүр була. Шул сәбәптәндер, беренче сыйныфка кергән 18-20 укучыдан нибары 4-5 е генә башлангыч училищены тәмамлау бәхетенә ирешә.

1900 нче елда кыз балалар өчен дә махсус класс ачып җибәрәләр. Анда Хәбибулланың хатыны Алабугадагы шәһәр мәктәбен тәмамлаган Мөкәррәмә мөгаллимлек итә. Мәктәптә укучыларның саны 90 га җитә (62 малай, 28 кыз). Белемнәре һәм яшь зурлыклары буенча укучыларны 4 отделениегә бүләләр. Көн саен үткәрелгән фәннәргә дин сабагы, аңлатмалы уку, арифметика керә. Атнага дүрт тапкыр грамматика һәм язу, ике тапкыр славян теле һәм диктовка дәресләре үткәрелә. Мәҗбүри булмаган дәресләр исәбендә кул хезмәте һәм рәсем тора. Һади абый Исмәгыйлов истәлекләреннән без училищены уңышлы тәмамлаучыларга таныклык бирелүен ачыкладык. Аның исеменә бирелгән таныклыкның төп нөсхәсе бүген безнең музейда саклана. (кушымта 1 )

*"Безне урысча укырга, язарга, бигрәк тә сөйләшергә өйрәттеләр. Мин училищены уңышлы тәмамладым. Миңа таныклык бирелде. Чыгарылыш имтиханнарына Сарапул өязе халык мәктәпләре инспекторы һәм тагын Сарапулдан ике урыс учитель килделәр. Имтиханнар барлык фәннәр буенча урыс телендә барды. Урысчы язылды, укылды, хисап та урыс телендә чишелде",*- дип искә ала бу турыда Һади абый. [7, 66]

Мәктәпкә килүче балаларның саны елдан-ел артып тору сәбәпле, яңа бина төзү ихтыяҗы туа. 1900 нче елның җәендә авыл үзәгендә, бүген мәдәният йорты торган урында, барча халык көче белән төзелгән ике катлы агач бина калкып чыга. Аның беренче катындагы бер бүлмәсендә шул ук Тутаевлар нәселе кибет ачып җибәрә. Икенчесендә ирле-хатынлы мөгаллимнәр гомер итә башлый. Икенче катында ике укыту классы, ашханә барлыкка килә. Ләкин 1903 нче елның 1нче декабрендә Хәбибулла белән Мөкаррәмә авылдан китәләр. Алар урынына Мөкаррәмәнең бертуган абыйсы Солтангазиз Абдуллин атлы егет укытырга килә. Ул да Казандагы мөгаллимнәр мәктәбен тәмамлый. Әгерҗе җиренә килеп төшүгә, Тирсәдәге Шәмсекамәр атлы кыз белән танышып ала. 1904 нче елда Исәнбайда туй ясыйлар. Солтан малайларны укытса,



Шәмсекамәр кызлар укытучысы була. Мәктәптә укучы балалар саны 140 ка якынлаша. Мөхәммәдиева Бибимәрьям Фәррәхетдин кызы шул чор турындагы хатирәләрендә: *"Укытучы Солтангазиз абый ир балаларны, кыз балаларны хатыны Шәмсекамәр абыстай укытты. Агачтан салынган ике катлы, мөлаем матур бинаның ишекләре, идәннәре, баскычлары сарыга буялган, ялтырап торалар иде.*

*Чисталык, тәртип үтә җитди. Укытучылар ифрат белемле, шәфкатьлеләр булдылар. Авыл халкы да Солтангазизне үтә ихтирам итте....”*- дип яза. [ 7, 67]

1915 нче елда Солтанны Беренче Бөтендөнья сугышына, герман фронтына алып китәләр. Ләкин бер ел чамасы вакыт үтүгә үк, ул кабат Исәнбайга кайта һәм Шәмсекамәре белән бергә мәктәптә укытуын дәвам итә. Хәерчегә җил дә каршы дигәндәй, 1916 нчы елда мәктәпнең бинасы янып юкка чыга. Укуны өзмәс өчен, балаларны кабаттан элеккеге “иске” мәктәп бинасына – Әхмәтвәли йортына күчерергә мәҗбүр булалар. 1916-1917 нче уку елын мәктәптә Шәмсекамәр белән Әхмәтзыя Әхмәт Хафиз улы Хәкимов оештыралар. Укучылар саны 105 була. Кызганычка каршы, Солтангазиз хатынын туган авылына - элеккеге Ширәмәт хәзерге Түбән Кама районындагы Шәңгәлче авылына алып китә. [ 7, 67]

**1.2. Совет власте елларында башлангыч мәктәп.**

Октябрь революциясеннән соң, мәктәпне чиркәүдән (мәчеттән) аеру турындагы Декрет нигезендә барлык татар мәктәпләре дөньяви дәүләт мәктәпләре итеп үзгәртелә. Рус мәктәпләрендә православие дине сабаклары бетерелгән кебек, татар мәктәпләрендә дә ислам дине сабакларын укыту туктатыла. Халык мәгарифе системасы “Бердәм хезмәт мәктәбе турында”гы хөкүмәт Нигезләмәсе һәм һөнәри-техник белем бирү турындагы карары нигезендә Исәнбай мәктәбе дә «Бердәм хезмәт мәктәбе» дип атала башлый. Малайларны һәм кызларны аерым укытуны дәвам итәләр. 1927 нче елда мәктәптә 150 малай һәм 102 кыз укый. Малайларны Мөсифуллин Әкмәлетдин, Корбангалин Хафизетдин, Сундуков Шакир, кызларны Мөнәсыйпова Назифа, Бәширова Хәнифә, Мөнәсыйпова Хәдичәләр укыталар. [ 7, 69]

Архив материалыннан күренгәнчә, 1920 нче елларда укыту бик авыр шартларда барган. Мәктәпкә балаларны җыю 2 нче октябрьдән 10 нчы октябрьгә кадәр дәвам иткән. Ирләр мәктәбенә 150 ир бала, кызлар мәктәбенә 102 кыз бала язылган. Суыклар башланганчы, ике мәктәпкә дә балалар тулысынча йөриләр. Өскә һәм аякка киярлгә булмауны сәбәп итеп, күпләр мәктәпкә йөрүдән туктый. Нәтиҗәдә ир балалар - 110-111, кыз балалар 60 -70 тирәсе генә кала.

Мәктәп бинасы бик начар, иске хәлдә, утын мәсьәләсе ифрат авыр. Ике мәктәпкә дә урыс теле мөгаллиме җитми. Булган уку әсбаплары, китаплар, тузган хәлдә, битләре таралып беткән була. [7, 69]

Революциягә кадәр татарларның бик азы гына укырга, язарга өйрәнә алган. Бөек Октябрь революциясе җиңеп, Совет власте урнашу белән, массалар арасында наданлыкка каршы көрәш башлана. 1919 нчы елның 26 нчы декабрендә В.И.Ленин имзасы белән “РСФСР халыклары арасында наданлыкны бетерү хакында” декрет игълан ителә. Аның нигезендә 8 яшьтән 50 яшькә кадәр булган надан кешеләрне мәҗбүри рәвештә язарга, укырга өйрәтергә тиеш булалар. Бу декрет Исәнбай авылында да тормышка ашырыла башлый. Надан һәм аз белемле халыкны укыту эшенә нигездә укытучылар тартылалар. Шулай ук авылдагы барлык грамоталы кешеләр дә, укучы балалар

да бу эштән читтә калмыйлар. Аларны культармеецлар дип атыйлар. Культармеецлар надан халыкны библиотекада, мәктәптә, аерым йортларда укыталар. Йорт хуҗаларына керосин, утын, хәтта лампалар да бушлай бирелә. Балаларын имезүче хатыннарның, гарипләрнең өйләренә барып белем бирәләр. Укудан баш тартучылар, уку калдыручылар административ җаваплылыкка тартыла, акчалата штрафлар салына. [ 7, 96] Наданлыкка каршы көрәштә каты чаралар күрелүгә карамастан, бу эш бик авыр бара. Бигрәк тә Идел буендагы 1921 нче елгы ачлык зур кыенлыклар китереп чыгара. Укытучылар, балаларны саклап калу максатыннан, аерым өйләрдә ашханәләр оештыралар, аларны ашаталар, эчертәләр, ләкин ачлыктан үлүче 316 авылдашыбызның күпчелеге балалар була. 1930 – 1931 нче еллардан башлап кына бу эш җайга салына. Мәсәлән, авылыбыздагы 1934 елда алынган мәгълүматлар түбәндәгечә:

| | |
|---|---|
| Наданнар саны – 449 кеше | Аз белемлеләр – 188 кеше |
| Укытыла – 343 кеше | Укытыла – 47 кеше |
| Укытылып чыгарылды - 343 | Укытылып чыгарылды – 47 кеше |
| Укырга кабул ителүчеләр – 106 кеше | Укырга кабул ителүчеләр – 141 кеше |

Башлангыч белемне үзләштергәннәргә укып чыгу турында грамота да бирелә. [7, 162] Шундый грамоталарның берничә нөсхәсе безнең музейда да саклана.

1920 нче елларда илдә барган пионер – комсомоллар оешмалары төзү хәрәкәте безнең авылны да читләтеп үтми. 1929 нчы елда авылда беренче пионер оешмасы төзелә. Аны оештыручы 1 нче сыйныф укытучысы Корбангалин Ниязи була. Аңа бу эштә Шәйхетдинов Габдулла, Тютиев Заһидулла ярдәм итә. Оешмада 30 лап пионер исәпләнә. Отряд К. Ворошилов исемен йөртә, вожатые Даутов Мәхмүт була. Сундуков Мирзиян, Гарифуллин Фәйзи, Халиков Гаяз, Ризванова Җәүһәр, Тютиева Кәүсәрия, Ижболдин Әхмәт, Галиева Зәйтүнә, Гимаева Роза, Корбангалина Рәшидә, Мөсифуллин Фәтхи, Мөсифуллина Мөкәрәмә, Гыйльметдинов Мулла, Сабитов Салихҗан, Зиннәтуллин Салих, Төхбәтуллин Баян, Мукашев Ибраһим, Мухъяров Мирсәет, Ваһапова Мөшәрәфә, Ваһапов Сәгыйть иң актив пионерлардан саналалар. [ 7, 97]

Ул елларда пионер бүлмәсе аерым йортта урнашкан була һәм “Пионер клубы” дип йөртелә. Монда һәркөнне икешәр пионер дежур тора. Алар мичкә ягалар, су җылытып, идән юалар. “Пионер клубында” эш гөрләп тора: матур әдәбият китаплары кычкырып укыла, күңелле җырлар өйрәнелә. Өлкән вожатый Корбангалинның сөйләвен балалар тын да алмыйча тыңлап утыралар. Пионер сборлары да еш үткәрелә. Пионерлар көче белән металл ватыклары, чүпрәк, сөяк, кәгазь җыела, тимурчылык эше колач җәя. Шулай ук алар арасында хәрби – спорт уеннары оештыруга да зур игътибар бирелә.

## II бүлек. Җидееллык совет мәктәбе.

### 2.1. 1931 – 1941 нче еллар.

СССР ның БКП (б) ҮК һәм ХКСның 5 сентябрь 1931 елгы "Башлангыч һәм урта мәктәп" карары нигезендә совет мәктәбенең яңа үсеш этабы башлана.[21, 112] 1931 нче елдан Исәнбай башлангыч татар мәктәбе тулы булмаган урта мәктәп (җидееллык) итеп үзгәртелә. 1931 – 1932 нче уку елында яңа мәктәптә - мәктәп карамагына бирелгән элеккеге волость башкарма комитеты бинасында 5 нче сыйныф ачыла.



1931 нче елдан пионер отрядлары мәктәпләрдә оештырыла башлый. Мәктәп пионер эшчәнлегенең үзәгенә әверелә. Пионерга бары тик иң алдынгы укучыларны гына кабул итәләр. Төп игътибар укуга юнәлтелә. Пионерлар рейдлар үткәрәләр, йомшак укучыларны шефлыкка алалар. Атна саен пионер эшчәнлеген яктырткан "Прожектор" газетасы чыгарылып килә. Анда "2" легә укыган укучылар тәнкыйтьләнә, артта калганнарга юмористик шигырьләр языла. Газета һәрвакыт төгәл, чиста, дөрес булуы белән дә аерылып тора.[ 7, 96]

Спортка да зур әһәмият бирелә. Пионерлар оборона значокларын (БГТО, ГСО) алу өчен ярышларда бик теләп катнашалар. Тимурчылык эше киң колач ала: пионерлар йорт куяннары тәрбиялиләр, яңа оештырылган колхозның бозауларын шефка алалар, елга аръягындагы участокта яшелчә үстерәләр, ерымнарга каршы нарат агачлары утырталар, колхозның җирен ашлау өчен көл җыялар. Иң алдынгы пионерларны 1 айга Казанга ял йортына җибәрә, бүләкли торган булалар ( кушымта 2).

1931 нче елда беренче пионер лагере оештырыла. Ул күрше Усаклы авылы янындагы урманда урнаша. Пионерлар палаткалар корып ял итәләр, иң яхшыларын Малиновка авылындагы район лагерена җибәрәләр. Балалар бик тыйнак, тәмәке тарту дигән нәрсә дә бөтенләй булмый.

Пионерларның шул чордагы эшчәнлекләре турында Төхвәтуллин Исмәгыйльнең музейга язган хатында менә мондый юллар бар: *"Быргыны без "Мампасси" калаеннан, шулай ук барабанны да үзебез ясадык. Үзебез теккән байракларны тотып, урамда тантана итеп йөри идек. Кырда авылдашларыбызга хезмәт күрсәтүебезгә дә чиксез горурлана идек. Пионер сборлары да еш үткәрелә иде. Сбор быргы кычкыртып, барабан кагып башланып китә. Звено җитәкчеләре вожатыйларга рапорт биргәннән соң: "Пионер, һәрвакыт әзер бул!" дигән чакыруына без: "Һәрвакыт әзер!" дип җавап бирә идек. Кызыклы уеннар оештыруга аеруча әһәмият бирәләр иде. Җырлы- биюле уеннар да истә әле. Мәсәлән, "Күперле" уены. Пионерлар икешәрләп рәткә басалар. Рәт башында парсыз бер укучы була.Ул, башкалар җырлаганда, үзенә бер иптәш алып баса да, аларга багышлап төрле җырлар җырлыйлар. Кешеләр санынча, уен азакка кадәр дәвам итә."* [12]

Шул чорларның актив пионеры Гыймаева Роза апа: *“Крестьяннарны колхозга кертү өчен барган агитация-масса эшләрендә пионерлар актив эшләделәр. Керми калганнарга карата тәнкыйть шигырьләре яздылар...*

*Колхозыбызның җирен ашлау өчен, күпер башында көл җыя идек. Тимер – томыр, макулатура җыюда да ярыша-ярыша йөрдек...*

*Кичләрен укытучылар җитәкчелегендә авыл буенча походлар, уеннар, йолдызлар карау, олы чаналар белән тау шуулар бик яхшы истә калган”,*- дип яза. [ 3]

Сундуков Мирзиян абый истәлекләре исә пионерларның җыелган металл ватыкларын , 60 ат йөгенә төяп, Кызыл обоз белән Красный Борга илтүләре, шул исәпкә пионерлар өчен кирәкле әйберләр дә алып кайтулары турында сөйли. [7, 98 ]

1937 нче елдан Яңа ел бәйрәме үткәрелә башлый. Балаларга Яңа ел күчтәнәчләре – конфет, чикләвек, көнбагышлар өләшенә. Бәйрәмнең төп бизәге булып яшел чыршы тора.

7 ноябрь – Бөек Октябрь Социалистик революциясе, 1 май – Хезмәт ияләренең халыкара бердәмлеге көне бәйрәмнәрендә демонстрацияләр үткәрелә. Мәктәп балалары, укытучылар бу эшнең үзәгендә була. Алар, тигез сафларга - колонналарга тезелеп, быргы, барабан тавышлары астында авыл урамнарыннан үтә. [ 7, 59 ] Билгеле бер тәртиптә сафларга тезелеп, митинг, экскурсияләргә бару мәктәпнең традициясенә кереп кала.



**2.2. Мәктәп - Бөек Ватан сугышы елларында (1941-1945 еллар)**

1941 -1945 нче елларда, барлык совет халыклары кебек үк, мәктәбебез укучыларының тормышына “Ватан куркыныч астында” дигән тирән мәгънәле сүзләр уелып керә. ”Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен” дигән лозунг өлкәннәрне дә яшьләрне дә, балалар һәм укытучыларны да бер максатка – дошманны җиңүгә берләштерә. Сугышның беренче көне турында Җәмилева Зәкия апа ( ул вакытта укытучы) болай дип искә ала: *“Авылда Сабан туе. Тигез сафлар белән барабан һәм быргы тавышлары астында мәктәпнең пионер дружинасы килә. Алар, колхозчыларны котлап, чыгыш ясыйлар. Пионер дружинасы башлыгы Ризванова Шәфыйка 72 пионерның уку елын яхшы билгеләренә тәмамлавы турында белдерә, җәйге кыр эшләренә актив катнашырга өнди.*

*Укучылар концерт номерлары башкаралар. Уен-көлке, җыр белән кичнең якынлашуы сизелми дә. Авыл ягыннан, ашыгып-ашыгып, берәү чабып килә. Ул колхоз башлыкларын җыеп сөйләшкәннән соң, авыл советы рәисе, сугыш башлануын белдереп, митинг ача. Пионерлар да, илне фашист илбасарларыннан тар-мар итүгә көчләрен кызганмыйча эшләячәкләрен, тырышачакларын белдереп, өйләренә таралалар.”* **[**1**]**

Исәнбай мәктәбе укытучылары да сугышның беренче көненнән үк фронтка китәләр. Мәктәп директоры һәм тарих укытучысы Ситдыйков Әхмәт Ситдыйк улы, башлангыч класслар укытучысы Ханнанов Нәгыйм Мәннән улы, математика укытучысы Тютиев Сәет Гобәйдулла улы сугышның беренче елларында ук батырларча һәлак булалар. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәлиуллина Фатыйма Хәбибрахман кызы исә үзе теләп фронтка китә. Галиуллин Миндерахман Шәех улы 1942 нче елны, авыр яраланып, туган авылына кайта һәм озак еллар физкультура укытучысы булып эшли. Шакиров Мөхәммәт, Ямалиев Лотфулла, Мозаффаров Сәлим, Тукманов Гариф, Ижболдин Касыйм, Якупов Мирзанур абыйлар да, сугыш газапларын күреп, орден-медальләр белән бүләкләнеп, туган авылларына исән-сау әйләнеп кайталар. Сугыштагы батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән, 1957-1966 нчы елларда мәктәп директоры булып эшләгән Табаров Зәки Идрис улы; сталинградчы, Кызыл Йолдыз, Сугышчан Дан орденнары, медальләр иясе, 1971-1979 нчы елларда мәктәп директоры булган Танашев Минлихан Яманай улы турында да мәктәп музеенда якты истәлекләр саклана. (кушымта 3)

1941 нче елның җәе укучылар һәм укытучыларны кыр эшләренә тарта. Мәктәп директоры Даутов Мәхмүт абыйның язмаларыннан күренгәнчә, мәктәптәге 338 укучының 185е кыр эшләрендә актив катнаша. Алар барлыгы 3612 хезмәт көне эшлиләр. VI класс укучысы Хуҗин Фәрит - 115, V класс укучысы Җәлилов Локман 100 хезмәт көне эшли.

Һәрбер укытучы колхоз производствосында катнаша. Мәсәлән, кырда эшләүче Якупова Роза 16 сотый урынына - 30 -35, Галиева Зәйтүнә 25 -30 сотый җир уралар. Укытучы Ситдикова Һәдия, балалар бакчасы мөдире булып, 360 хезмәт көне эшли. [ 1

Пионерлар, колхозда эшләү белән беррәттән, мәктәпне яңа уку елына да үзләре әзерлиләр. 7 нче август көнне, мәктәпкә җыелып, ремонт эшләре башлап җибәрәләр. Егетләр мич чыгару өчен кирпеч ташыйлар,туфрак салалар, кызлар классларны юалар, җыештыралар, тәрәзәләр куялар. Тиз арада мәктәп яңа уку елына тулысынча әзерләнеп бетә.

Укытучы-парторг Даутов Мәхмүт абый инициативасы белән авылдагы ике колхозда да кызыл олау оештырыла. Митинг ясап, дошманны тизрәк җиңү өчен, сугыштагы әтиләргә, абыйларга ярдәм йөзеннән 97 олау ашлык хөкүмәткә озатыла. Бу Кызыл олауда мәктәптән 10 укытучы, 23 укучы йөк белән бара. [ 1 ]

Бөек Ватан сугышы елларында дару үләннәре җыюның әһәмияте тагын да арта. Пионерлар сугыш елларында аптекага 257 кг дару үләннәре җыеп тапшыралар. Исмәгыйлева Лилия апа язмасыннан нинди үләннәр икәнен дә белә алдык: “ Җәй көне .. әрәмәләрдән валериан тамыры, урыс кычытканы кебек үләннәр җыя идек”,-дип яза ул.[6]

Машина-трактор станциясенә дә балаларның ярдәме күп тия. 1943 нче елда укучылар Исәнбай МТСы өчен 3,5 ц чүпрәк (ремонт ясаганда тракторларны юарга), авыл хуҗалыгы машиналары өчен запас частьләр җыеп тапшыралар. Ә уку елы азагында Исәнбай МТС участогы авылларындагы пионерлар слеты

була. Политбулек слет уткәрүне укытучы Даутов Мәхмүткә тапшыра. Слетның ничек үтүен Җәмилева Зәкия апа истәлекләреннән белергә була: “*15 нче июнь иртәсе. Мәктәп матур итеп бизәлгән. Тәрәзә төпләрендә ал, кызыл һәм зәнгәр чәчәкле гөлләр. Залның стеналары төрле картиналар, киселгән рәсемнәрдән берничә төрле темага күргәзмә һәм лозунглар белән бизәлгән. Өстәлләрдә төрле уен кораллары һәм газета журналлар. Бер өстәлдә бер төркем пионерлар патефон уйнатып утыралар. Болар әле Исәнбай мәктәбе пионерлары иде. Сәгать 10нар җитте. Билгеләнгән укучылар һәм укытучылар авыллардан слетка киләчәк пионерларны каршы алырга киттеләр.*

*Менә мәктәп бакчасы. Бакча ерактан ук үзенә тартып тора. Тигез озынлыкта куе булып тезелеп үскән агачлар, чәчәк клумбалары арасында утыргычларда юлда арып килгән пионерлар рәхәтләнеп ял иттеләр. Барлык авыллардан пионерлар җыелып беткәч һәм ял иткәч, сигналчы спорт мәйданында, сузып-сузып, сигнал уйнады. Пионерлар тиз генә парадка тезелделәр. Һәр пионер држивасы начальнигы слет начальнигына рапорт бирде. Парад үткәрелде. Парадтан соң клубта слет башланды. Ерактан ук пионерларның көчле “Ур-ра” тавышлары, кул чабулар, барабан һәм быргы тавышлары яңгырап торды. Пионерлар слеттан канәгать булып таралдылар.”*[1]

1943 нче елда, укучыларны кайнар аш белән тәэмин итү максатыннан, колхоз мәктәпкә 8 га җир участогы бүлеп бирә. Анда арыш, солы, борчак культуралары чәчелә, бәрәңге һәм яшелчәләр утыртыла. Участокта укытучылар һәм укучылар бик тырышып эшлиләр. Хәзерләнгән продуктлардан кайнар аш пешерә башлагач, укучыларның дәрескә йөреше яхшыра. Участокта һәр кыш саен балалар кар тоталар, тирес чыгаралар, уңышны күтәрү өчен көчләрен кызганмыйлар.

Сугыш чорында республика укучылары арасында тимурчылык хәрәкәте киң җәелә. Исәнбай мәктәбе укучылары да бу хәрәкәттән читтә калмыйлар. Алар ирләре фронттагы гаиләләргә ярдәм итәләр, су ташыйлар, салам алып кайталар.

Сугыш елларында укучылар һәм укытучылар фронтовик балаларына бик зур ярдәм күрсәтәләр. Бу хакта без музейдагы “Ватан сугышы елларында Исәнбай мәктәбе” дигән җыентыктан укытучы Борисова Кәүсәрия апа язмаларын укып белдек. Мәктәп коллективы фронтовик балаларына әйбер җыю айлыклары оештыра. Мондый айлыклар, гомумән, республика күләмендә үткәрелгән. Бу хакта “Социалистик Татарстан” газетасының 1980 нче ел 9 нчы май санында дөнья күргән “Тыл – фронтка” рубрикасында менә ничек языла: “1944 нче елның 15 ноябреннән 16 нчы декабренә кадәр республикада фронтовик балаларына, мәктәпләргә һәм балалар йортларына ярдәм айлыгы уздырылды. Бу чорда 1505519 сум акча кертелде.”

Шундый айлыкларның берсендә безнең Исәнбай мәктәбе укучылары гына да түбәндәге күләмдә әйбер тапшырган:

Тире -33данә<br>
Йон – 6кг<br>
Төрле кием- 24 данә<br>
Бәрәңге -667кг

Акча – 900сум. [1]

Күпме генә чаралар күрелсә дә, фронтовик балалары тиешенчә мәктәпкә йөри алмыйлар. Чөнки аларның киярләренә булмый. *“Дәрескә йөри алмаучылар күбәйде. Безне укырга килмәүчеләрне җыярга җибәрәләр. Минем Хәкимова Галимәне чакырырга барганым исемдә. Әнисе иске итек күтәреп чыкты. Итекнең ямар җире дә калмаган. “Кызым, 3 кешегә менә шушы итек бар. Мин кисәм, балаларга юк, алар кисә, миңа юк,” -дип, елап җибәрде. Ул бала, шулай итеп, укуны бетерә алмады,”*-дип яза үзенең истәлекләрендә укытучы Исмәгыйлева Лилия апа. [6] Шуңа күрә мәктәп, фронтовик балаларының укырга йөрүләрен тәэмин итү өчен, 1944-1945 нче уку елында 40 пар киез итек, 20 күлмәк, 12 чүәк җыеп бирә. [ 8]

Чыннан да, ул елларда укыту бик авыр шартларда бара. Кием-салымнар начар булуы өстенә, балаларның ашарларына да җитәрлек булмый. Укырга китаплар, дәфтәрләр җитешми. Укытучы Гыймаева Роза апа истәлекләреннән без*: “Әле дә хәтердә: беренче класста 43 укучыга нибары бер “Әлифба, язарга да үзебез сызып ясаган дәфтәр. Өлкән класс укучылары иске китап араларына язып укыйлар. Мәктәп иске, салкын, ягарга җитәрлек түгел. Кыш вакытында, көннәр кыска булу сәбәпле, караңгыга калып укытырга туры килә. Җиделе, унлы лампадан төшкән яктылык бик начар иде”,* - дигән сүзләрне укыйбыз.[3]

Фашистлар илебезгә бик күп зыян китерә. Барлык халык ярдәменнән башка бу җимерекләрне торгызу мөмкин дә булмый. 1942 нче елдан, Кызыл Армия илебез территориясеннән берничә йөз чакрымнарга дошманны куып җибәргәч, илдә фашистлардан азат ителгән районнарга ярдәм итү хәрәкәте оештырыла. Безнең авылыбыз мәктәбе укучылары да бу хәрәкәттә бик теләп катнашалар. Музейдагы И.В.Сталинга юлланган телеграмма копиясе моңа дәлил булып тора*: “Кадерле Иосиф Виссарионович Сталин! Татарстан АССР Красный Бор районы Исәнбай җидееллык мәктәбе укытучылары һәм укучылары немец илбасарлары тарафыннан җимерелгән мәктәпләрне торгызу фондына 20000 сум акча керттеләр. Сезгә, Иосиф Виссарионович, дошманга курку һәм безнең куәтле, күп милләтле Советлар Союзының даны өчен озын гомер һәм сәламәтлек телибез.*

*Мәктәп директоры Даутов, уку-укыту мөдире Җәмилева, учком председателе Нәҗметдинов.” ( кушымта 4)*

Бу телеграммага җавап итеп, И.В.Сталиннан 1944 нче елның 31 нче маенда телефонограмма алына: *“Мәктәп директоры Даутовка, уку-укыту мөдире Җәмилевага, учком председателе Нәҗметдиновка. Исәнбай мәктәбе укытучылары һәм укучыларына немец илбасарлары тарафыннан җимерелгән мәктәпләрне торгызу фондына 20000 сум акча җыйган өчен минем кайнар сәламемне һәм ССР Союзы хөкүмәтенең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм. И.В.Сталин” ( кушымта 4)*

Бу хатлар 1944 нче елның 9 нчы июнендә районда нәшер ителүче “Колхоз ярышы” газетасында да басылып чыга. Газетаның бу нөсхәсе бездә саклана һәм, аны кулга алып укыган саен, авылдашларыбыз белән горурлану хисләребез тагын да көчәя.

Бу акча авылыбыз мәктәбе өчен бик зур сумма була. Чыганаклар белән эшләгәндә, шундый фактка юлыктык: Арча районыннан барлыгы 40000 сум акча һәм китаплар, савыт- сабалар җибәрелгән. [21, 117 ] Чагыштырып карасак, безнең бер мәктәптән генә дә тулы бер районнан җыелган сумманың яртысы кадәр акча тупланган. Кайдан алганнар  соң авылдашларыбыз бу сумнарны? Укытучы Борисова Кәүсәрия апа сүзләренә караганда, алар мәктәп яны участогында яшелчәләр үстереп сатканнар. Ә ул чактагы укучы Хәкимов Назиф абый безгә: *“Мин, кайтып, җимерелгән мәктәпләрне торгызу фондына әнидән акча сорадым. Ул миңа биш сум бирде. Бу акчаны алгач, сөенә-сөенә, мәктәпкә барганымны бүген дә яхшы хәтерлим,”*- дип сөйләде. [18] Димәк, халык үзенең һәм балаларының авызыннан өзеп булса да, илне, аның җимерекләрен торгызуда кулыннан килгән кадәр акчалата һәм әйберләтә ярдәм иткән.

Эзләнүләр барышында мәктәп коллективының Бөек Ватан сугышы чорында тагын бер мөһим инициатива белән чыкканын күреп горурландык. 1944 нче елның язында мәктәп укучылары һәм укытучылары колхоз атларын шефлыкка алалар. Алай гына да түгел, райондагы укучыларны һәм укытучыларны бу эшкә өндәп, йөкләмә-хат  язалар. Районда чыга торган «Колхоз ярышы» газетасының 1944 нче ел 20 нче апрель  санында “Исәнбай авылы тулы булмаган урта мәктәбе укучыларының һәм укытучыларының райондагы барлык укучыларга йөкләмә хаты”

*“Кадерле иптәшләр!*

*Һәрбер иртәне шатлыклы дулкынлану белән каршылыйбыз. Кызыл Армиянең көннән-көн алга баруы, илебезнең немецерткычларыннан көннән-көн тиз чистартылуы безне канатландыра. Илгә, фронтка, батыр әтиләребезгә һәм абыйларыбызга дошманны тизрәк тар-мар итү өчен кулдан килгән барлык ярдәмне күрсәтү теләге белән янабыз.*

*Без, Исәнбай авылы тулы булмаган урта мәктәбе укучылары, җыелышып сөйләштек, киңәштек тә, язгы чәчүне уңышлы тәмамлап чыгу өчен, колхозга чын укучыларча ярдәм итү  турында  карарга килдек. Икмәк өчен көрәш - безнең җиңүебез өчен көрәш тә бит. Без моны бөтен тирәнлеге белән аңлыйбыз.*

*Язгы чәчү эшләрен вакытында үтәп чыгу атка бәйләнгән. Атлар көр, арып калмаслык булганда гына, югары иген уңышы өчен көрәш  уңышлы хәл ителәчәк. Шуның өчен без колхоз атларын шефка алырга булдык һәм түбәндәгеләрне  үзебезнең өскә  йөкләмә итеп алабыз:*

1. *Кыр эшләре башланганчы һәм кырга чыккач, атларны көн саен ике мәртәбә кыргычларбаз, чистартырбыз.*
2. *Атларның ашау вакытларында ныклы күзәтү булдырырырбыз. Ат ризыгының аяк астына коелып, әрәм- шәрәм ителмәвенә ирешербез.*
3. *Үлән чыгу белән үк, атлар өчен капчыклап, үлән җыю эшенә керешербез. Чәчүдә, сөрүдә, тырмада һәм башка кыр эшләренә тартылган атларга кырда ял вакытында ашату өчен үлән җыеп илтербез, төнгелек өчен дә аларга үлән җыеп салырбыз.*

*Бу йөкләмәләрне уңышлы итеп үтәү өчен, колхоз правлениесеннән һәрбер атка ике-өч укучыны беркетеп куюны сорыйбыз. Үзебезгә беркетелгән атларның көр булуын тәэмин итү өчен, үзара социалистик ярыш оештырабыз.*

*Бу эшләрне укытучыларыбыз җитәкчелегендә үткәрербез һәм үзебезнең арада аңлы дисциплина урнаштырырбыз.*

*Кадерле иптәшләр, совет мәктәпләре укучылары! Без үзебезнең өскә җаваплы гына йөкләмә алдык һәм намус белән үтәрбез.*

*Шуның белән бергә, без районнагы барлык мәктәп укучыларын да безнең башлангычыбызга кушылуларын сорыйбыз һәм җавап көтәбез.*

*Сүз безнең матур, шатлыклы яшьлегебезне тартып алырга теләүче дошманны тар-мар итү турында бара икән, без, укучылар, җиңү өчен көчебездән килгәннең бөтенесен дә эшләргә тиешбез.*

*Бер генә колхоз аты да укучылар шефлыгына алынмый калмасын".*

*Мәктәп директоры Даутов, комсомол оешмасы секретарьлары Борисова, Вәлиев, учком председателе Нәҗметдинов, укучылар Бәдретдинов, Шәйхетдинова, Ибатуллина һ.б.*

һәм бу турыда район советы башкарма комитетының һәм БКП/б/ райкомының карары басылып чыга.

*1. Кыр эшләре башланганчыга кадәр атларның торышын яхшыртуның һәм язгы чәчү вакытында аларның көрлекләрен саклауның гаять әһәмиятлелеген билгеләп үтеп, район советы башкарма комитеты һәм БКП(б) райкомы Исәнбай авылы тулы булмаган урта мәктәбе коллективының укучыларга аерым атлар беркетү юлы белән кыр эшләре башланганга кадәр аларга көндәлек тәрбия, күзәтчелек булдыру һәм язгы чәчү башлангач, эшләү урынына яшел үлән җыеп илтеп ашату турындагы инициативаларын яхшы дип табарга.*

*2. Райондагы барлык мәктәпләр коллективларына Исәнбай авыл тулы булмаган урта мәктәбе коллективының йөкләмә-хатын киң өйрәнергә һәм барлык укучыларның, укытучыларның, кыр эшләре башланганчы һәм язгы чәчүгә чыккач, атларга тәрбия, күзәтү булдыру өчен конкрет йөкләмәләр алуларына ирешергә, тәкъдим итәргә.*

*3. Район газетасы редакторларын үзләренең газеталарында колхозларда атларның эшкә сәләтлекләрен күтәрүдә һәм саклауда яхшы нәтиҗәләргә ирешкән мәктәп коллективларының тәҗрибәләрен киң күләмдә популярлаштыруга мәҗбүр итәргә.*

*Район Советы башкарма комитеты председателе Х. Шәрифуллин.*

*ВКП (б) райкомы секретаре Х. Әюпов*

Мәктәпләрнең, бу йөкләмә-хатны өйрәнгәннән соң, үзләренә йөкләмәләр алулары һәм аны ничек үтәүләре турында район газетасында күп кенә хәбәрләр языла. Безнең мәктәпнең эше турында да газетага хәбәрләр җибәрелә. Мәсәлән, "Кызыл Татарстан" газетасының 1944 нче ел 23 нче апрель санында "Яхшы башлангыч" дигән түбәндәге мәкалә чыга: *"Красный Бор, 21 апрель.(Телефон буенча) Исәнбай авылындагы мәктәп укучылары язгы чәчүдә колхозларга булышлык итү буенча файдалы эш башлап җибәрделәр. Биредә 200 дән артык укучы "Фрунзе" һәм "Комбайн" исемендәге колхозларның барлык атларын*

*шефка алдылар. Алар көн саен ат абзарларын һәм атларны чистарталар. Атларны вакытында ашатуларын күзәтәләр. Һәр атка ике укучы беркетелде. Укучылар шефлык итә башлагач, атларның торышы сизелерлек төстә яхшырды. 18 ат түбән көрлектән уртачага күтәрелде инде һәм кыр эшләренә җигү өчен яраклы хәлгә китерелде.”* [ 1 ]

Исәнбай авылы укучылары атларны шефка алу турында районның барлык укучыларына мөрәҗәгать иткәннән соң, яшь патриотлар үрнәгендә районның 2 меңнән артык укучысы колхоз атларын шефлыкка алалар.

Мәктәп укучыларына һәм укытучыларына сугыш еллары аеруча авыр була, чөнки укырга да, өйдә эшләргә дә, колхозга булышырга да кирәк. Музейда саклана торган фотокарточкалардан без бу чорда укыган балаларның йөзеннән дәһшәтле елларның күләгәсен күрәбез.



5 нче, 6 нчы сыйныфларда укучы бу сабыйлар, нәни генә куллары белән зур эшләр башкарып, җиңү таңын якынайталар. Аларның батырлыгы тиңдәшсез. Аларның сабырлыгы безгә үрнәк.



Бу эшләрне башлап йөрүчеләр һәм җитәкләүчеләр – укытучылар. Хөкүмәтебез дә аларның мондый кыю адымнарга баруын хуплый һәм вакытында тиешле бәясен дә бирә. 1947 нче елда биш укытучы - Даутов М., Даутова Ф., Гыймаева Р., Ризванова Җ., Җәмилева З.- ләр - берьюлы “Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен медале” белән бүләкләнә.

Балачаклары сугыш чорына туры килгән авылдашларыбыз мәктәптә укыйсы урынга эшләргә мәҗбүр булалар. Хөкүмәтебез аларны да игътибардан читтә калдырмый, өлкәннәр белән беррәттән, “1941 – 1945 нче елларда Бөек Ватан сугышында күрсәткән хезмәттәге батырлыгы өчен” медале белән бүләкли. Шунысы кызыклы, безнең музейда ике таныклык саклана. Аларның икесе дә бер үк елны, бер үк көнне, бер үк гаиләгә - әнисе һәм улына – Халикова Мәхмүдә апа һәм Халиков Рәис абыйга бирелгән.( кушымта 5) Алар 1941 нче елда ук сугышка киткән ире һәм әтисе Халиков Сабир урынында колхоз атларын караучылар булып эшләгәннәр. Димәк, мәктәп яшендәге балаларның хезмәте дә бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле һәм файдалы булган.

## III бүлек. Урта мәктәп.

### 3.1 Урта мәктәпнең беренче адымнары.

Сугыштан соңгы авыр еллар, торгынлык чоры. Мәктәптә белем алу өчен кирәкле шартлар юк, махсус белемле укытучылар җитми. Мәктәп директоры Даутов Мәхмүт абый 10 еллык мәктәп ачу артыннан йөри башлый. Укыту өчен бина кирәклеге зур проблема булып килеп баса. Укучылар җыелышында өч мәчет бинасын берләштереп, мәктәп төзү турында сөйләгәч, укучылар үзләре булдыра алган эшләрдә катнашырга теләк белдерәләр. Өмә ясап, мичләрне сүтәләр, кирпечләрне ташып, өеп куялар. Шулай ук кыска бүрәнәләрне һәм сайгакларны ташуда да укучылар зур булышлык күрсәтәләр. Директор Даутов үзе дә дәрестән тыш вакытларда балта осталары белән бергәләп эшли. Укытучылардан Галимуллин, Шакирова һәм Якуповалар да мәктәп төзүдә актив катнашалар. Шулай итеп, күмәк тырышлык белән 1949 нчы елда авылда урта мәктәп ачыла. Унъеллык мәктәп ачылу укучыларга белем алуга зур этәргеч була. Югары уку йортларына керү мөмкинлекләре туа.

1951 нче елда урта мәктәпнең беренче чыгарылышы була. Менә алар беренче карлыгачлар: Ахметова Галимә, Ижболдина Гөлсәрия, Нәҗметдинова Рәшидә, Ситдыйкова Рабига, Хакимов Назиф, Хисматуллина Тәнзилә, Шакиров Раил.

Мәктәптә уку әсбаплары, кабинетлар җитешмәүгә карамастан, бу укучылар үзләренең тырышлыклары нәтиҗәсендә мәктәпне уңышлы тәмамлау бәхетенә ирешәләр һәм күбесе укуларын югары уку йортларында дәвам итәләр. Үзләренең тормышын киләчәк буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган Ситдыйкова Рабига, Ахметова Галимә, Шакиров Раил, Ижболдина Гөлсәрия, Хисматуллина Тәнзиләләр - бу башлангычның беренче җимешләре. Алар арасында Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, туган авылыбызда үз хезмәтен куйган Хәкимов Назиф абый да бар.

1952 нче елда Исәнбай урта мәктәбенә директор итеп Әминов Гаяз билгеләнә. Бу елны тагын 6 укучы кулларына өлгергәнлек аттестаты алалар. 7 нче класс программасын уңышлы гына үзләштереп, 8 нче класста 32 укучы укуларын дәвам итсәләр дә, 10 классны бары 6 укучы гына тәмамлый. Укуның түләүле булуы (елга 150 сум), тормыш авырлыгы күп кенә укучыларны укуларын ташларга мәҗбүр итә. Ләкин һәр чорның үз истәлекләре, күңелле вакыйгалары бар. 1952 нче елда мәктәп тәмамлаган укучылар да (хәзер инде апа-әбиләр, абый-бабайлар) мәктәп елларын сагынып искә алалар. Җәмилә апа Якупова үзенең рус теле укытучысы һәм класс җитәкчесе Мария Александревна, завуч Гаскәр абый Бәширов, немец теле укытучысы Лилия Заһриевна Шәрәфиева, математика укытучысы Зәкия Маликовна турында гел җылы сүзләр белән генә искә алды.

Исәнбай урта мәктәбен 1953 нче елда 10 укучы тәмамласа, 1954 нче елда 11 егет һәм кыз кулларына өлгергәнлек аттестаты алалар.Ә 1955 нче елдан укуга, белем алуга дәрте, тырышлыгы булган барлык укучыга урта белем алу мөмкинлеге туа, чөнки белем алу түләүсезгә әйләнә. [7,166]

Мәктәп үз тормышы белән яши. Класстан тыш эшләр бигрәк тә җанланып китә. Атнага бер тапкыр танцы түгәрәге була. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Бәширов Гаскәр һәм пионервожатый Энҗе Гарифуллина укучыларны биергә генә түгел, культурага, яңалыкка да өйрәтәләр. Бу хакта хәзерге вакытта пенсионер укытучы Рубина апа Танаева болай дип сөйли : *“Кайдан килгәндер, анысын хәтерләмим. Кечкенә генә гәүдәле, бик җитез, матур Энҗе апа оста биюче иде. Ул безнең мәктәпкә төрле халык биюләре, костюмнарын алып килде. Төрек, үзбәк, татар, рус, испан, чех һ.б. халык биюләләрен безгә дә өйрәтте, үзе дә бик матур бии иде.”*[ 9 ]

Хәзерге вакытта лаеклы ялда булган Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы Зарипова Фәтхия апа болай дип өсти: *“Без, Тукманов Һабил, Мөхәммәдяров Фаиз, Минһаҗева Фәүзия, Сабитова Фәтхия, район фестивалендә бию буенча I урынга чыгып, концертлар белән йөрдек. Ә чех халык биюе белән республикабыз башкаласы Казанга баруга лаек булдык.”*[ 4 ]

Гаскәр Бәширов җитәкчелегендә мәктәптә “Беренче адымнар” дигән яшь әдәбиятчылар түгәрәге оештырыла. Бу түгәрәк бик күпләр өчен әдәбият, сәнгать дөньясына юл күрсәтүче йолдыз була. Түгәрәккә йөрүчеләр “Яшь әдәбиятчы” газетасын чыгара башлыйлар. Монда укучыларның мәкаләләре, шигырь, фельетоннары урнаштырыла. Газета укучыларның игътибарын бик тиз биләп ала. Аны чыгаруда катнашырга теләүчеләр артканнан арта һәм, ул мәктәпнең тормышын чагылдырган айлык газетага әйләнә. [2]

Гаскәр абый әдәбият сөюче һәр баланың күңел дөньясына үтеп керә, “шигърият чире”н йоктыра. Бүгенге көндә Татарстанның язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Гөлзадә Әхмәтова-Ягъфарова; “Сөембикә” журналы хезмәткәре - журналист Зәлидә Әкберова; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәһимә Сабитова; балалар җырлары авторы Гөлсинә Гәрәева; Халык Мәгарифе отличнигы Фәридә Нәҗмиева; Татарстанның атказанган мәктәп укытучылары Г.Шәймәрданова, Г.Исмәгыйлева; 2 китап авторы (“Язмышым канатында”,“Кояш исе”) Әлфирә Низамовалар - Гаскәр Фәссах улы Бәшировның “Беренче адымнар” кульязма газетасыннан иҗат дөньясына кереп китә алган элеккеге укучылары.

Ә 1958 нче елдан “Беренче адымнар” түгәрәгенә йөрүчеләр “Яшьлек” исемле айлык әдәби кульязма журнал чыгара башлыйлар. Журнал яшь хәбәрчеләр, әдәбиятчылар, булачак язучылар өчен олы юлга якты маяк була. Бу журналның №1 санында фронтовик- язучы М. Хөсәен белән очрашу турында мәкалә бирелгән: *“14 январьда шагыйрь М. Хөсәен белән очрашу кичәсе булды. Шагыйрь үзенең шигырьләрен сөйләде... “Көмеш чабаклар” исемле китабын бүләк итеп калдырды. Анда түбәндәге сүзләр язылган: “Исәнбай мәктәбенең укучыларына, кыю һәм акыллы патриотлар булып үсүләрен теләп, чын күңелдән. М. Хөсәен.”* (кушымта 6)

Әйе, бу елларда мәктәптә пионер һәм комсомол оешмалары, укучылар үзидарәсе гөрләп эшли. Бу чорларда мәктәптә укучылар өчен пионер һәм укучылар формасы кертелә. 1963 нче елда  мәктәптә беренче тапкыр чыгарылыш сыйныф укучылары урта белем турындагы аттестат белән бергә тракторист-машинист профессиясе алулары турында таныклык та алып чыгалар.



Мәктәп тормышын кызыклы, мавыктыргыч итү өчен бар мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышалар. Укучылар сәнгатьтә, спортта, төрле ярышларда актив катнашалар. Район, хәтта республика ярыш-смотрларында призлы урыннар яулыйлар. Күңелле хатирәләр саклана укучылар хәтерендә. *"Мәктәп ишек алдындагы каток бүген дә күз алдымда минем. Гариф Шафикович тарафыннан оештырылган иде ул. Бима елгасыннан су ташып, без, укучылар, каток һәм аның тирәсенә төрле җәнлек сыннары ясадык. Мәктәпнең ботинкалы конькилары һәм дәресләрдә укучыларга җитәрлек чаңгылары бар иде. Барыбыз да рәхәтләнеп шуабыз, уйныйбыз. Кыш көне мәктәп ишек алдында боз уенчыклар белән бизәлгән чыршы да безнең өчен бик матур һәм кадерле иде,"*- дип, үзенең хатирәләре белән уртаклашты Фәтхия апа Зарипова.
[ 4 ]

**3.2. Алга – яңа үрләргә**

1957 нче елдан мәктәп белән җитәкчелекне Зәки Идрисович Табаров үз кулларына ала. Яңа килгән директор бик тиз укытучылар коллективы белән уртак фикерләр бердәмлеге булдыра. Мәктәп коллективы укыту-тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген, белем бирүнең сыйфатын күтәрү максатларында ике төп проблема- "Укучыларны совет халкының революцион-сугышчан һәм хезмәт традицияләрендә тәрбияләү " һәм "Мәктәп укучыларының танып белү активлыгын күтәрү" проблемалары өстендә шөгыльләнә башлый.

Элеккеге хезмәт укытучысы Ижболдин Касыйм болай дип искә ала: *"Тынгысыз директор, шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, яшьләрчә, бөтен булган көчен биреп, мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту өстендә эшләде. Агачтан машиноведениә кабинеты, мәктәп өчен магазин йорты, яшелчәләр саклау базы, теплица һ. б. күп кенә төзелеш эшләре башкарылды. Район мәктәпләрендә беренчеләрдән булып яңа трактор алуга иреште.*

*Барлык класс кабинетлары да утын ягып җылытыла иде. Әйтергә генә ансат, ягу сезонына 300 куб м чамасы утын китә (19 мич ягыла иде). Моннан тыш әле укытучыларга да күпме утын кайтарырга кирәк иде. Зәки Идрисович барлык утынны җәй көне кистереп, ярдырып, киптереп түбә астына урнаштырта. Шуның нәтиҗәсе буларак, классларда һәм интернатта һәрвакыт нормаль температура була иде."* [ 5]

Профориентация юнәлеше мәктәпнең көн тәртибе мәсьәләсенә әйләнә. Авыл өчен үзебезнең кадрларны - укытучылар, медицина, авыл хуҗалыгы белгечләре әзерләү мөһим бурыч булып алга баса. Мәктәп нәкъ менә шушы юнәлештә нәтиҗәле эш оештыра да инде. Бүгенге көндә район, республикабыз мәктәпләренең күбесендә Исәнбай мәктәбеннән чыккан укытучылар хезмәт куя. Шунысы да кызыклы: аларның күбесе - җитәкчеләр. Юкка гына ул елларда, укытучылар хезмәтенә зур бәя булып, зур трибуналардан район хакимияте тарафыннан “Исенбаевская школа кует пед кадры” дигән сүзләр яңгырамагандыр. [13]

60-70 елларда коммунистлар партиясе тарафыннан бөтен ил буенча урта белем бирү мәсьәләсе бик көчле куела. Бу мәсьәләне тормышка ашыруда кичке мәктәпләрнең роле бик зур була. Исәнбай мәктәбе укытучылары да үзләренең вакытлары белән исәпләшмиләр, зур хезмәт куялар. Эштән соң егетләр-кызлар кичке мәктәпкә бик теләп йөриләр, тырышып укыйлар, белем серләренә төшенәләр. Дәресләр 19.00.- 23.00.сәгатькә кадәр дәвам итә. Әлбәттә, укытучыларның түземлелегенә, эш дәртенә, энтузиазмына, яшьләрнең тырышлыгына, максатчанлыгына сокланырга гына кала. Ә бит кичке мәктәпне тәмамлаучылар арасыннан ныклы белемле кадрлар чыга. Шәрәфиев Заһит – югары белемле агроном, Ягъфаров Гаяз –Кызыл Байрак хезмәт ордены белән бүләкләнә, Тютиев Сәгыйть – КДУ тәмамлый, озак еллар парторг булып эшли; Ижболдин Касыйм – Механик, Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый, хезмәт укытучысы булып эшли.[ 13 ]



1960 нчы елларда ил күләмендә башланып киткән Ленин музее, бүлмә, почмаклары оештыру хәрәкәтенә Исәнбай мәктәбе дә кушыла. 1965 нче елда В.И. Ленинның тууына 95 ел тулу уңаеннан мәктәптә Ленин бүлмәсе ачыла. Бу хакта музей истәлекләре менә нәрсәләр сөйли: *“Без, интернатта тәрбияләнүче балалар, тәрбиячеләр һәм хезмәткәрләр, Исәнбай урта мәктәбенең укытучылар һәм укучылар коллективы көче белән оештырылган Ленин бүлмәсендә булдык. Без монда В. И. Ленинның тормыш һәм революцион эшчәнлек еллары белән таныштык. Әйтергә теләгән нәрсәләрне сүз белән генә әйтеп бирүе кыен. Безнең йөрәкләрдә туган Ильичка, Туган илебезгә, Халыкка, партиягә карата зур мәхәббәт саклана.*

*Беренче тапкыр Исәнбай авылында Ленин бүлмәсе оештырылу һәм анда күргәннәр безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.*

*Интернатта торучы балалар, тәрбиячеләр- Хабибуллина,*

*Шарипова 22.04 - 65 ел* [8]

Бу елларда мәктәптә укучылар саны елдан ел арта бара, чөнки Исәнбай мәктәбе тугызбуй якларында бердәнбер урта мәктәп була. Укучылар саны кискен рәвештә арту сәбәпле, укыту класслары, интернатлар төзү бурычы кичектергесез эшләр булып тора.

Зәки Идрисович мәктәптә эшләү дәверендә агач буралардан гомуми мәйданы 120 кв.м. булган ике интернат төзетә, кирпечтән гомуми мәйданы 128 кв.м булган йорт җиткертә. Агачтан брусоклар ярдырып, ике класс укырлык йорт салдырта.

1956 нчы елдан эшли башлаган интернатта, якын-тирәдәге ун авылдан килеп,



Исәнбай мәктәбендә укучы балалар яши. Мәктәп директоры З.И.Табаров интернатта яшәүче балаларның тормышларын яхшыртуга бик зур игътибар бирә. Тәрбиячеләр булып, Галиева Зәйтүнә, Борисова Кәүсәрия эшли. Тукманов Гариф балаларны гармунда, мандолинада уйнарга өйрәтә. Балалар бергәләшеп вакытлы матбугат материаллары белән танышалар, әдәби әсәрләр укыйлар, фикер алышалар. Тематик кичәләр үткәрү, концертлар кую күңелле, мавыктыргыч эшләрнең берсе була. *“Монда һәрчак идеаль тәртип, реанимациядәге кебек чисталык хөкем сөрде. Тәрәзә төпләрендә берсеннән берсе матур гөлләр, стеналарга чигүләр эленгән иде. Болар укучылар кулы белән эшләнә. Балалар режим буенча яшиләр. Бар нәрсәдә төгәл тәртип. Дүшәмбе көнне дәресләргә соңга калмас өчен, укучылар якшәмбе кичтән үк килергә тиешләр. Зәки Идрисович соңга калучыларны бер дә яратмый, аларга таләпләр дә каты иде,* - дип искә ала Фәтхия апа Зарипова.[4] Үзенең традицияләрен дәвам итеп, интернат 1985 нче елга кадәр яши.

Укытучы, укучы, ата-аналар бердәм булып эшләгәндә генә мәктәп югары нәтиҗәләргә ирешә ала. Шуны күздә тотып, мәктәптә айга бер тапкыр ата-аналар университетлары эшли башлый. Атнага бер тапкыр радиочыгышлар оештырыла, ата-аналар мәктәп яңалыклары, уку-укытуның торышы белән таныштырыла. Күрше авылдан килеп укучы балалар да игътибар үзәгендә тора. Укытучылар, трактор арбаларына төялеп, күрше авылларга (10авыл) ата-аналар җыелышы үткәрергә йөриләр. Партия кушуы буенча, төрле темаларга докладлар укыйлар, агитация эшләре алып баралар. [13]

Мәктәп бу елларда үзенең производство бригадалары белән дә үзенчәлекле. Укучылар укытучылар җитәкчелегендә эзләнү-тикшеренү, тәҗрибә эшләре алып баралар.

5 нче класс пионерлары Сабитова Ф., Усманова Ә., Ибатуллин И., Борһаниев Г., Вахитов Б., Җәмилев М., Мөхәммәдьяров Ф., Мәннәнова Р-лар вожатый



Шәйхетдинова М. Ш. җитәкчелегендә куяннар тәрбиялиләр. Куян ояларын аларга комсомоллар ясап бирә. Һәр көнне икешәр кеше дежур тора, куяннарга өчәр тапкыр ашау бирәләр, ояларын чистарталар. Пионерларның максаты, куяннарны күбрәк үстереп, колхозның оештыралачак куян фермасына тапшыру, итне күбрәк җитештерүдә дәүләтебезгә ярдәм итү була.
[ 4 ]



Ә 9-10 нчы класс комсомоллары бригадасы кукуруз үстерү буенча тәҗрибә үткәрә. Бригада членнары, апрель өмәсендә үк, кукуруз участогына тирес чыгаралар. Участокны берничәгә бүлеп, һәрберсенә төрле ашламалар кертәләр, җәй көннәрендә чүпләрен утыйлар, карап, тәрбияләп торалар. Кукуруз нинди ашлама белән яхшы үскәнен билгелиләр.[13]

Мәктәп үзенең алма бакчасы белән дә дан казана. Төрле сортлы алмагачлар алып кайтып утыртыла. Борисова Кәүсәрия бакча мөдире була. Укучылар белән төрле тәҗрибәләр үткәрәләр, алмагачларны ялгыйлар, карап тәрбияләп торалар. Бакча да елдан ел зур уңышы белән куандыра.

Каникул вакытларында исә укучылар колхозга бозау карарга булышалар. Мәктәп "Кече ферма"сы оештырып, бер ат һәм ике дуңгыз карыйлар. Моның өчен махсус бригада төзелә. Алар график нигезендә эшлиләр. Ат мәктәп хуҗалыгында файдаланылса, дуңгызларны сатып, аннан кергән акчага мәктәпнең материаль-техник базасын тулыландыралар. (диапроектор ЛЭТИ сатып алына)

Шулай итеп, "Илгә файдалы шул, кем кече яшьтән үк хезмәт белән яши" ("Полезен только тот стране, кто с малых лет живёт в труде") девизы астында илдә барган пионер һәм комсомол оешмаларының хезмәт эстафетасында Исәнбай мәктәбе дә уңышлы эш алып бара.

1963 нче елдан башлап "Рассвет" колхозы Исәнбай урта мәктәбе белән



берлектә колхозчы балалары өчен "Салют" пионер лагере оештыралар.Ул нарат урманында Күмерсәү елгасы буенда урнаша. Бу традиция 1982 нче елга кадәр дәвам итә.

Палаткалар шәһәрчегендә көн буе балаларның шат авазлары, быргы, барабан тавышы тынмый. Йолдызлы төнне яктырткан пионер учаклары тирәсендәге җыр-бию, уеннар, поход-экскурсияләр, колхозга ярдәм, дару үләннәре җыю, табигать кочагында яшәүне онытырга мөмкинме соң? Хәбибуллина Инглизәнең истәлек язмалары да раслый моны: *"Һәр елны нарат урманында урнашкан "Салют" пионерлагеренда ял итә идек. Без анда табигатьнең матурлыгын күрергә, тоярга, аны сакларга, үзара дус –тату булырга, мөстәкыйльлеккә, хезмәтне яратырга, чисталыкка-пөхтәлеккә өйрәндек. Һәр иртәдә безне быргы тавышы йокыдан уятты. Тар сукмак буйлап челтерәп аккан чишмә буена юынырга барулар, иртәнге линейка, вожатыйлар белән берлектә үткәрелгән төрле кызыклы чаралар, спорт ярышлары, походлар, колхозчылар алдында концертлар куюлар әле дә бүгенгедәй хәтеремдә."*[15]

**3.3. Уңышлар куанырлык**

З.И. Табаров җитәкчелек иткән чорда тупланган традицияләрне мәктәп директорлары Бәширов Гаскәр Фәссәхович (1966-1972) һәм Танашев Минлехан Яманаевич (1972-1979) 70 нче елларда нәтиҗәле дәвам иттерәләр.



1969 нчы елда яңа мәктәп өчен фундамент салына. Мәктәпне җиткерүне финанслаучы “Рассвет” колхозы була. Бу эшкә мәктәп директоры Г.Бәширов та зур көчен куя. 1973 нче елда 320 урынлы ике катлы бөтен уңайлыклары –ашханә, спортзал, китапханә һәм 12 фән кабинеты, техник хезмәт һәм производство нигезләренә өйрәтү остаханәләре булган яңа типовой мәктәп ачыла. Бу авыл халкы өчен сөенечле зур вакыйга була.




Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту, укытуда кабинет системасына күчү укучыларга ныклы һәм тирән белем бирүгә ярдәм итә. “4-5” легә укучыларның саны үсә, 100 % өлгереш бирүче класслар арта. Бу исә үз чиратында укытучыларның да үз белемнәрен, профессиональ осталыкларын күтәрү, яңа методик алымнар куллануларын таләп итә. Бу елларда укыту-тәрбия эшчәнлеге үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Мәктәп “Укучыларның танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү” дигән проблема өстендә уңышлы эш алып бара. Укыту процессының нәтиҗәлегенә ирешүдә фәннәр буенча үткәрелгән класстан тыш чараларның да роле зур була. Тәҗрибәчелек, тематик кичәләр, китап укучылар конференцияләре, кызыклы очрашулар, яшь әдәбиятчылар, танцы, музыка, география, кино сөючеләр түгәрәкләре, мәктәп радиоузелы тапшырулары һ. б. фәннәрне яхшырак үзләштерүгә һәм яшь буынны тәрбияләүгә зур мөмкинлекләр тудыра.

Мәктәп яны тәҗрибә участогында тәҗрибәчелек эше тагын да зуррак уңышларга ирешә. Бу эш белән биология укытучысы Хәкимова Асия җитәкчелек итә. Бакчаны зурайтып, җиләк-җимеш агачлары утырту, аларны тәрбияләү, уңыш алу күп хезмәт сорый. Бакча эше бөтен мәктәп укытучылар һәм укучылар эшенә әверелә, ел саен күп итеп җиләк-җимеш, яшелчә культуралары хәзерләү гадәткә керә. Мәктәп тәҗрибә участогы ел саен район күләмендә призлы урыннар гына яулый. (кушымта 7) Тырыш хезмәт югары бәягә дә лаек була. 1967-1975 нче еллар дәвамында Исәнбай мәктәбе тәҗрибә участогы һәм производство бригадасы эше буенча ТАССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең I дәрәҗәдәге Дипломы, ике тапкыр II дәрәҗәдәге Дипломы һәм кыйммәтле бүләкләргә лаек була. Укучы Шәрипова Халидә экспонатлар белән ВДНХга карлыган үстерү буенча тәҗрибә уртаклашырга бара. Мәктәп исеме республикага таныла, ә тәҗрибә кишәрлегендә үстерелгән

яңа сорт бодайны карарга Республика яшь натуралистлар станциясеннән дә киләләр.[17]

Татар әдәбияты түгәрәге бигрәк тә нәтиҗәле эш алып бара. Аңа татар теле һәм әдәбияты укытучысы Г.Г. Саттарова җитәкчелек итә. Бу әдәби түгәрәк берләшмәсе утырышларында әдәбият белән кызыксынучы һәр укучы катнаша ала. Биредә туган телнең үзнчәлекләре өйрәнелә, татар язучыларының әсәрләренә анализ ясала. Түгәрәк члennары аның утырышларында үзләренең шигырьләрен, хикәяләрен, пьесаларын укыйлар, иҗади эш буенча киңәшләр алалар. Ә яхшы дип табылган шигырьләр һәм хикәяләр концертларда, кичәләрдә һәм колхоз радиоузелы аша укылалар.

Мәктәптә һәр ай саен “ Беренче адымнар” дигән стена газетасы чыгарып барыла. Анда әдәби түгәрәк члennарының әсәрләре урнаштырыла. Берничә ел дәвамында “Әтиләр һәм әниләрнең данлы юлы буйлап”, “Авылдашлар - Бөек Ватан сугышында катнашучылар”, Әниләргә бүләк”, “Мәктәп еллары” һ.б. исемдә әдәби җыентыклар чыгарыла.

Организатор Зарипова Фәтхия Наҗиевна, пионервожатый Сундукова Гүзәлия Заһриевналар эшләгән дәвердә З.Космодемьянская исемендәге пионер дружинасы районда иң алдынгылардан санала һәм берничә ел рәттән ( 1974 – 1978, 1982, 1986 нчы еллар) профориентация, хезмәт, тимурчылык, хәрби патриотик юнәлешләрендә, сәнгать өлкәсендә, кыскасы, барлык юнәлешләрдә уңышлы эш алып барганы өчен уң флангтагы дружина исеменә лаек була. (кушымта 8 )

“Пионер төзелеше” маршына кушылып, безнең дружина “Пионер прожекторы” газетасы республика күләмендә үткәрелгән стена газеталары конкурсында җиңүче исеменә лаек була һәм “Яшь ленинчы” редакциясенең Мактау кәгазе белән бүләкләнә. Тимурчылык хәрәкәте дә мактауга лаек икәнен, “Яшь ленинчы” газетасында ( № 93, 1972 нче ел) басылып чыккан И.Хәбибуллина мәкаләсе раслый.

*“8865*

*Беркөнне “Кем күбрәк?” дигән девиз астында тимер ватыклары җыю буенча өмә үткәрдек. Кызыл галстук таккан пионерлар мәктәп ишек алдына агыла башладылар. Өмә кызганнан- кыза барды. Кичкә 8865 килограмм тимер ватыгы җыйналды. Павлик Морозов, Валентина Николаевна Терешкова, Муса Җәлил исемендәге отряд пионерлары тимер ватыгын күп җыйдылар. С.Хәкимов, А.Исмәгыйлов, А.Ахунҗанов һәм М.Вахитовка тиңнәр булмады. Аларның нәтиҗәләре —300 –270 килограмм.”*

Газетада чыккан мәгълүматлар белән чагыштырып карасак, Лаеш, Түбән Кама, Югары Ослан, Чүпрәле, Балык Бистәсе, Чирмешән районнары пионерлары нибары 0,5-4әр тонна тимер ватыгы җыйганда, безнең мәктәп укучылары үзләре генә 8865 кг металлолом җыеп озатканын күрәбез.

Мәктәп хәрби-патриотик тәрбия бирү юнәлешенә зур игътибар бирә. ”Салют, җиңү!” республика Кызыл эзтабарлар хәрәкәтенә кушылып, пионерлар сугыш ветераннарына, сугышта һәлак булган авылдашларыбызга, герой-шәһәрләргә багышланган альбомнар төзиләр; “Сугышчан дан” почмагына материаллар туплыйлар. Совет Армиясендә хезмәт итүче авылдашларыбыз белән хатлар

алышалар, очрашулар уздыралар, һәм бу материаллар “Солдат хатлары” альбомында урын ала.

Һәр ел саен кыш көне үткәрелә торган “Аҗаган” уенын укучылар көтеп алалар. Ул “Без – булачак солдатлар!” девизы астында ике этапта уза. Бу уен булачак солдатларны физик һәм рухи ныклыкка, түземлелеккә, тапкырлыкка һәм зирәклеккә өйрәтә, Ватанга тугрылык хисләре тәрбияли. Ә җәй көне пионерларның, Красный Борга барып, гражданнар сугышы каһарманы В. Маркин һәйкәле янында сбор үткәрү һәм венок салулары традициягә әйләнә. [8]

Якташыбыз Шаршады авылы егете Әнвәр Зәйнетдинов, Совет- Кытай чиген саклаганда, 1968 нче елда батырларча һәлак була. Район күләмендә, аның батырлыгына багышлап, ел саен пионер дружиналары төрле чаралар үткәрә. Шундый чараларның берсендә зур кунак - шагыйрь Мостафа Ногман катнаша. Бәйрәмдә 10 класс укучысы Фәридә Нәҗмиева герой егет Әнвәр Зәйнетдиновның әнисенә багышлап үзе язган “Герой анасына” дигән шигырен укый. Мостафа Ногманга бу шигырь бик ошый һәм ул аны үзе белән ала. Бәйрәмнән алган тәэсирләр нәтиҗәсендәдер, шул ук класс укучысы Фәридәнең якын дусты Гөлсинә Гыйльфанова, өйгә кайткач, гармунына утыра һәм, үзе дә сизмәстән, шигырьне көйгә сала. Шатлыклы хәбәрне дусты белән уртаклашырга чаба. Менә шулай Исәнбай укучылары иҗат иткән бу шигырь республикада популярлашып китә һәм халык арасында “Син көтәсең һаман улыңны”(халык көе) исеме астында җырлана башлый.[15] ( кушымта 9)

Укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирүдә тарихи истәлекле урыннарга, герой- шәһәрләргә экскурсияләр оештыруның әһәмияте зур була. Бүгенге көн укучылары өчен башка республика, илгә бару чынга ашмастай хыял кебек тоелса, 70 нче елларда ул мәктәбебезнең үзенчәлекле гадәти бер күренешенә әйләнә. Ел саен колхоз идарәсе ярдәме белән иң яхшы укучылар Мәскәү, Ленинград, Киев, Одесса, Брест, Волгоград, Казан, Минск, Витебск кебек. шәһәрләрдә, Хатынь мемориаль комплексында экскурсияләрдә булалар.

Мондый сәяхәтләр балалар һәм укытучылар күңелендә онытылмаслык хатирәләр калдыра. Укучылар төзегән альбомнарда түбәндәге юллар саклана: “*Җиңүнең 30 еллыгы алдыннан герой-шәһәр Волгородка укучыларны экскурсиягә алып бару укучыларның да, үземнең дә күңелдә җуелмаслык эз калдырды. Волгоград шәһәренең сугыш күз яшьләре, кеше гомерләре белән сугарылган истәлекле тарихи урыннары белән танышып йөргәндә, халкымның батырлыгына, түземлелегенә сокланып таң каласың. Сугыш уты безнең республикабыз башкаласыннан шактый еракта йөрсә дә, халкым йөрәгендә батыр улларын югалту хәсрәтеннән тирән эзләр сызылган шул. Безнең сөекле Казаныбызның Ирек мәйданында яраткан шагыйребез Муса Җәлилгә куелган һәйкәлгә дә укучылар белән берничә ел экскурсиягә бардым. Анда укучылар аның үлемсез шигырьләрен укудылар, чәчәкләр куйдылар. Шулай ук Казандагы башка истәлекле урыннар, музейлар белән танышу, Ленин йөргән эзләрдән Казанда һәм Ленино-Кокушкинода булу да хәтерләрдә мәңге сакланыр”,*- дип яза пионервожатый Сундукова Г.З. [15]

Белоруссиягә сәяхәт турында үзләре төзегән альбомда укучылар түбәндәгеләрне язып калдырганнар: *“Ямьле җәй айлары килеп җитте. Безне,*

*ягъни укуда тырышып укучы һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашучыларны, туган колхозыбыз "Рассвет" союздаш республика – Белоруссиягә туристик путевка белән бүләкләде. Бу көн безнең иң бәхетле көннәрнең берсе булды, хыялыбыз тормышка ашты.*

*Укытучыларыбыз Гүзәлия һәм Рабига апалар җитәкчелегендә, без ерак сәяхәткә чыгып киттек.*

*Белоруссия җире безне бик ягымлы, кунакчыл каршы алды. Сәяхәтнең башы Новополоцк шәһәреннән башланды. Безне анда бик чиста, якты, әйбәт җиһазланган кунакханәгә урнаштырдылар. Һәр көн билгеле бер программа буенча үтте. Без музейларда, соборларда ... һ.б. булдык. Маршрутның дәвамы герой- шәһәрләр- Минск һәм Витебск булды. Витебсктагы Шмырев музеенда күргәннәр бездә тетрәндергеч тәэсир калдырды. Фашистларның ватандашларыбызны җәберләгән төрле җайланмаларын, төрмә стенасында язылган канлы эзләрне күреп, халкыбызның батырлыгына сокландык, ә явыз илбасарларга карата нәфрәтебез тагын да артты. Инде сугыш бетеп, 40 елга якын вакыт узса да, шәһәр эчендә яу эзләрен күрсәтеп торган җимерек йортлар да бар иде. Витебск халкының сугышта 2/3се батырларча һәлак булуын белгәч, күзләребезгә яшь тулды. Исем фамилияләре күрсәткән китаплар гына да әллә ничә иде бит...*

*...Без сәяхәт иткән автобус "Хатынь" дип билгеләнгән күрсәткечтән уңга, кара төстәге асфальт юлга борылды. Хатынь... Бу авыл картада билгеләнмәгән. Анда бары тик көлгә әйләнгән хәрабәләр генә сакланган. Фашистлар бу авылны яндырып юк иткәннәр. Җил искәндә, Хатынь бөтен җир шарына үзенең 36 чаңы белән аваз сала һәм шуны чаңнар бөтен җир шарын тынычлыкка өнди. Хатынь авылында үзенең үле газиз баласын күтәргән ана һәйкәле басып тора. Ул Белоруссиядә сугыш вакытында фашистлар тарафыннан кешеләре тереләй яндырылып, җир йөзеннән юкка чыгарылган авыллар истәлегенә куелган. Һәйкәлдән тере чәчәкләр бер вакытта да өзелми. Чал чәчле бабайлар, әбиләр үзләренең оныкларын ияртеп бирегә килә. Аларның күзләреннән атылып чыккан яшь бөртекләре шул чордагы вакыйгаларның ничаклы куркыныч булуы турында сөйли иде."* [15]

70 нче елларда мәктәптә үзешчән сәнгатькә зур игътибар бирелә. Май аенда укучылар, табигатькә чыгып, матур аланда сәхнә ясыйлар һәм шунда класслар арасында смотр концерты – фестиваль үтә. Шундый фестивальләрнең берсе СССР төзелүнең 50 еллыгына багышлап үткәрелә һәм ил күләмендә гаять зур әһәмияткә ия була. "Социалистик Татарстан" газетасының бер санында Хәбибуллина Инглизәнең мәкаләсе басылып чыга.

*"Безнең мәктәптә күңелле һәм файдалы кичәләр, кызыклы очрашулар еш уздырыла. Бөек юбилей — СССР төзелүнең 50 еллыгын бәйрәм итүгә хәзерлек чорында очрашулар, дуслык кичәләре аеруча истә калырлык булды.*

*Кичәләрнең берсе СССР халыклары дуслыгына багышланган иде. Мәктәпнең һәр өлкән классына икешәр союздаш республика турында сөйләргә өйрәнергә кушылды. Укучылар союздаш республикалар турында материаллар җыйдылар, әңгәмәләр үткәрделәр, альбомнар һәм стендлар төзеделәр. Шулай ук милли ашлар пешерүдә осталыкларын күрсәтергә дә әзерләнделәр.*

*Безнең кичәгә чакырылган кунакларыбыз — Иске Чекалда сигезьеллык мәктәбе укычылары да килде. Без аларны ипи һәм тоз белән каршы алдык. Очрашу кичәсен мәктәпнең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Фәридә Шәймөхәммәтовна Арсланова ачты. Ул үзенең чыгышында мәктәпнең зур юбилейны ничек каршылавы турында сөйләде. Аннан соң зал бердәм рәвештә “Нинди иркен минем туган илем” җырын башкарды. Шул вакытта союздаш республика вәкилләре булып киенгән укучылар сәхнәгә үттеләр. Алар үз республикалары турында дәртләнеп сөйләделәр. Кунаклар Г.Тукманованың молдаван, Л.Шәйхетдинова, Ф.Сундуков, З.Хөснетдинова, Р.Аскаровларның татар халык биюен башкаруларын сокланып карадылар.”*

Мондый фестивальләрдә Исәнбай мәктәбе, районда җиңү яулап, республика күләмендәге ярышларда да катнаша. Мәктәпнең хор һәм бию коллективы зур уңышларга ирешә. Район күләмендә җиңү яулап, грамоталарга лаек була. (кушымта 10) Районда җиңү яулаган Ф.Сундуков, Р. Хуҗин, Г.Галиева, Л. Шәйхетдиновалар составындагы бию коллективы “Кара песи” биюе белән һәм Сундуков Фәрит мәктәбебез укучылары Нәҗмиева Ф.(сүзләре) Һәм Г.Гыйльфанова (көе) иҗат иткән “Герой анасына” (“Син көтәсең һаман улыңны”) җыры белән Казанда пионериянең 50 еллыгына багышлап үткәрелгән республика смотр фестивалендә уңышлы чыгыш ясыйлар. Ф.Сундуков фотоаппарат белән бүләкләнә.[15]



Чыннан да, бу елларда мәктәп һәм пионер оешмасы эшчәнлеге югары дәрәҗәгә куелган була. Мәктәпнең иң алдынгы укучысы Якупов Илсурның Бөтенсоюз пионер лагере “Артек”ка путевка белән бүләкләнүе – моны раслаучы тагын бер дәлил. Бу урында Илсурның истәлекләрен бирү урынлы булыр . *”Мин , бөек совет иленең гади бер пионеры, Артекта булу бәхетенә ирештем.*

*Артек гаҗәеп лагерь икән. Сул яктан таулар, уң яктан урманнар безнең корпусны бизиләр иде. Ул Кара диңгез буена урнашкан. Диңгез кайчакларда бик шаулап, ә кайбер чакларда, киресенчә, тыныч кына тора. Артекны 1925 елны Зиновий Петрович Соловьев җитәкчелегендә төзи башлаганнар: Анда башта дүрт кенә палатка булган. Бары тик 80 генә кеше ял итә алган. Ә хәзер бер сменага 5000 кеше ял итә ала. Без 7нче смена идек. Хәзер Артекта зур корпуслар. Без 13 отрядта 42 шәр кеше ял иттек. Безгә пионер киемнәре бирделәр. Без анда атнага дүрт мәртәбә, бишәр сәгать укыдык. Дружинада мине өлкән быргычы итеп билгеләделәр. Быргы кычкыртуда уңышларым өчен мине “Юному горнисту” дигән эмбелема белән бүләкләделәр. Отрядлар арасында күп кенә ярышлар үткәрелде. Бу ярышларда безнең отряд икенче урынны алды. Һәм безгә зур конфет бирделәр. Ул конфет бик зур иде, аны ике кеше көчкә күтәреп алып кайтты. Аның эчен ачып карасак, һәрберебезгә дә майкалар һәм бик күп итеп конфет салынган иде. Без андагы конфетларны көлешә-көлешә ашадык. Мин иркле илдә-совет илендә яшәвем белән*

*горурланам. Безгә, балаларга, бәхетле балачак, якты киләчәк бүләк иткән Ленинга, Партиягә, хезмәтчел совет халкына рәхмәтемне белдерәм.”*

Якупов Илсур 1972 елда “Артек”та булса, 1981 нче елда бу бәхет фидакяр хезмәте өчен пионервожатый Сундукова Гүзәлиягә елмая. *"Күп еллар районда дружина “Уң флангтагы дружина” исемен йөрткәне, алдынгы булганы өчен комсомол райокомы мине 1981нче елда Бөтенсоюз пионер лагере “Артек”ка бушлай путевка белән бүләкләде. Бу минем өчен пионер тормышына бәйле иң истәлекле көннәр булып хәтердә калды, әлбәттә. Пионер яшендә нинди генә бала хыялланмый икән шушы бәхет илендә булырга!*

*“Артек”ның символы – дуслык. Дөньяның бөтен континентларыннан да пионер эшендә активлык күрсәткән, яхшы укыган балалар монда үзләренә ял итү мөмкинлеге алалар. “Артек” нинди җир соң ул дигән сорауга “Если песню, улыбку и дружбу сложить и на яркое солнце умножить” дип җавап бирәләр. Монда һәркем өчен күңеленә охшаган эш табыла, чөнки 20 түгәрәк эшли. Зур, якты мәктәп, стадион, бассейннар, автобаза, диңгез порты, пляжлар – рәхим ит – барысы да синең өчен. Ял итүче балалар пионер активы эшен дөрес, җанлы, күңелле итеп оештыруның күпкырлы яклары белән танышалар, дуслык, иптәшлек, намуслык законнары белән яшиләр.*

*Без анда 15 союздаш республика вәкилләре бер семьядай дус яшәдек, бер-беребез милләтенең гореф-гадәтләре, союздаш илләр турында күп нәрсәләр өйрәндек. Артекның үз традицияләре дә бик күп. Артек хатирәләре ямансу булып калмасын өчен, 50нче елларда монда бик матур традиция уйлап тапканнар. Соңгы кичәдәге саубуллашу костереның күмерләрен истәлеккә өләшәләр. Алар, хатларга әйләнеп, илебезнең төрле почмакларына оча, Артектагы дуслык озак еллар хатлар аша дәвам итә. Безнең дружина да Украина, Белоруссия, Үзбәкстан пионерлары белән хатлар алышты... ”*[15]

1981 нче елда Гүзәлия Заһриевнага ВЛКСМ Үзәк комитеты Мактау грамотасы бирелсә, 1982 нче елда В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер организацияләренең Үзәк Советы Мактау грамотасы белән бүләкләнә һәм “Вожатый- инструктор” исеменә лаек була. Бу, әлбәттә, бөтен дружинаның эш нәтиҗәсе. (кушымта 11 )

1975-1980 нче еллар - мәктәптә спорт эшләренең күтәрелеш чоры. Физкультура укытучысы Герман Танаев җитәкчелегендә киләчәк җиңүләргә нигез салына башлаган чор бу. Спорт түгәрәкләре, секцияләр гөрләп эшли. Анда укучылар зур теләк һәм кызыксыну белән шөгыльләнәләр. Берсеннән берсе кызыклы төрле ярышлар үткәрелә: күңелле стартлар, эстафеталар, баскетбол, волейбол һәм чаңгы буенча мәктәп беренчелегенә ярышлар, ”Ягез әле,егетләр!” һ.б



Г.Танаев, тренер буларак, сәләтле, физик яктан нык укучылар белән нәтиҗәле эшли. Аларның сәләтләрен, мөмкинлекләрен үстерүгә зур көч куя. Нәтиҗәдә чаңгы, баскетбол, волейбол буенча мәктәп командасы район күләмендә берничә ел рәттән гел

алдынгы (I-III) урыннарны гына яулап килә. Түбәндәге таблицалар шул хакта сөйли.

Мәктәпнең иң яхшы чаңгычылары (1976-1980 еллар)

| Укучының фамилиясе, исеме | Нәтиҗәләре |
|---|---|
| Тухватуллин И. | II урын |
| Галимова З. | III урын |
| Якупов И. | II урын |
| Маннанова Р. | II урын |
| Альманов Р. | I урын |
| Гарифуллина Г. | I урын (өч ел рәттән) |
| Минекаева Г. | I урын, район чемпионы |
| Хабиров Ф. | I урын (өч ел рәттән) |
| Ханнанова Х. | II урын |
| Якупов Г. | I урын |
| Назмутдинов И. | I урын |

Баскетбол буенча да 1975-1980 нче елларда мәктәпнең җыелма командасы район күләмендә үткәрелгән ярышларда уңышлы чыгыш ясыйлар, I- II урыннардан төшмиләр. Ә 1980 нче елда җыелма команда Кукмарада республика ярышларында катнашып,район данын яклыйлар.

Тренер, физкультура укытучысы Танаев Герман Иванович турында укучыларда якты хатирәләр генә саклана.

*"Герман абыйның физкультура дәресләре бик кызыклы үтә иде. Ул укытканда, безнең мәктәп беренчелектән төшмәде. Герман абый балаларны ачуланмый, оста укытучы. Ул үзенең эшен бик яратып башкарды һәм аның ярдәме белән күп кенә укучылар физкультура укытучылары булдылар. Физкультура дәресләреннән тыш, ул мавыктыргыч ярышлар үткәрә иде. Без, аның укучылары, яшьтән үк чыныгып үстек. Шуның өчен Герман абыйга һәрвакыт рәхмәтлебез." (Тукманов Илнур)*

*"Безне 9-10 класста Герман Танаев укытты. Ул безне спортны сөяргә, мәктәп данын яклау өчен, барсын-барсын эшләргә өйрәтте. Без күп җирләргә ярышларга йөрдек. Мәктәпнең җыелма командасы белән төрле ярышларга йөр, безне нык ихтыярлы, түземле, төгәл булырга өйрәтте. Герман абый үз эшен хөрмәт итеп, аны һәрвакыт яратып башкарды. Ул-үз эшенең остасы. Без аны бик яраттык." (Мухъянова Халисә)*

*"Танаев Герман-мәктәп тарихында тирән эз калдырган, укучылары күңеленә мәңгелеккә кереп калган физкультура укытучысы. Ул эшләгән елларда үткәрелгән төрледән-төрле спорт ярышлары, кызыклы кичәләр, экскурсияләр үзе бер гүзәл хатирә булып йөрәкләрдә саклана. Көнне төнгә ялгап, мәктәптән кайтмыйча, алны-ялны белмичә эшләде ул. Физкультура дәресләре балаларның түземсезлек белән көтеп алган, иң яраткан дәресләре иде. Рухи яктан да, физик яктан да чыныккан, көчле ихтыярлы, җитез, төгәл балалар үстерү – бу Герман абыйның зур теләге иде. Ул бөтен көчен, бөтен барлыгын шуңа багышлады. Рәхмәтебезнең олысы сезгә, Герман абый."(Гарифуллина Гөлнур)*

Безнең фикеребезчә, 1970- 1980 нче еллар - безнең елъязмабыздагы искиткеч еллар.

**3.4 Эстафета дәвам итә.**

1980 – 1983 нче елларда мәктәп директорлары гел алышынып тора: 1979-1980 – Исмәгыйлева Г.Г., 1980-1981 – Вафин С. Б., 1981-83 – Насыйров А. Н., 1983 нче елдан Тукманов М. Г. җитәкчелек итә башлый.

Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан ил күләмендә "Беркем дә, бернәрсә дә онытылмасын" девизы астында сугышта һәлак булганнарның исемен мәңгеләштерү, тарихыбызны туплау, өйрәнү максатыннан зур эшләр башкарыла. Исәнбай мәктәбендә авыл һәм мәктәп тарихын чагылдырган музей ачу көн тәртибенә килеп баса, чөнки инде авыл һәм мәктәп тарихы турында материаллар шактый тупланган була (болар Корбангалин Н. кульъязмалары, директор Даутов М. Һәм эзтабарлар җыйган материаллар), әмма борынгы экспонатлар, истәлекләр җитешми. Укучылар тарих укытучысы Зарипова Ф. Н. җитәкчелегендә, өйдән-өйгә йөреп, экспонатлар, фотосурәтләр, хатлар, документлар җыялар, истәлекләр язып алалар. Музейга материаллар җыю мәктәп эше генә түгел, бөтен авыл халкы эшенә әйләнә һәм уртак хезмәт нәтиҗәсе буларак, 1985 нче елда "Сугышчан һәм хезмәт даны" залы булган "Туган якны өйрәнү" музее ачыла.

Материалларны түбәндәге бүлекләргә урнаштыралар:

1. Нумизматика.
2. Язма чыганаклар бүлеге.
3. Фронт хатлары, орденнар, медальләр.
4. Хезмәт кораллары һәм көнкүреш әйберләре.

Һәр бүлекнең үзенең укучы экскурсоводлары була. Музей хәрби-патриотик эшнең үзәгенә әверелә. Бу темага уза торган дәресләрнең дәвамы еш кына музейның "Сугыш һәм хезмәт даны" залында уза. Музей эшчәнлеге укучыларда халкыбызның хезмәт, патриотик, туган илгә мәхәббәт традицияләрен тәрбияләүдә зур роль уйный. Мәсәлән, Әфганстанда интернациональ бурыч үтәгәндә күрсәткән батырлыклары өчен Шәрәфиев Ә. З. "Кызыл Йолдыз" ордены һәм "Батырлык өчен" медале, Юсупов Ф. – "Батырлык өчен" медале, Чечня республикасында Латыйпов Ф. Һәм Исмәгыйлев Р. "Батырлык өчен" ордены белән бүләкләнәләр.

Музей эшчәнлегендә "Туган якны өйрәнү" түгәрәгенең роле бик зур. Алар, "Экскурсовод", "Эзләнүчеләр", "Яшь хәбәрчеләр" дигән иҗат группаларына бүленеп, эзләнү эшләрен хәзер дә дәвам итәләр. Районыбызның башка мәктәпләрендә музейлар, сугышчан дан заллары оештыруда исәнбайлылар тәҗрибәсе өлге булып тора. 1989 нчы елда музейга, районда беренчеләрдән булып, "Мәктәп музее" статусы бирелә, таныклык тапшырыла.



"Туган якны өйрәнү" түгәрәгенең "Яшь хәбәрчеләр" группасы һәм "Беренче адымнар"(җитәкчесе Исмәгыйлева Г.Г.)

әдәбият түгәрәге бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торып эш алып бара. Укучыларның иҗади эшләре район, республика газета-журнал битләрендә урын ала. “Беренче адымнар” түгәрәгенең бер юнәлеше булып театр тора. Кечкенә балалар үзләре курчаклар тегеп, пьесалар язып, декорацияләр ясап, курчак театрлары кую белән шөгыльләнсә, ә өлкән класс укучылары драма әсәрләрен сәхнәләштерәләр. Түгәрәкнең эш тәҗрибәсе район, республика семинарларында еш гомумиләштерелә. Ә 1989 нчы елда мәктәп театр коллективы район халык фестивалендә Г. Камалның “Беренче театр” спектакле белән уңышлы чыгыш ясап, 1 нче урын яулый һәм Кукмарада үткән зона ярышларында 2 нче урынга лаек була.

Укучыларда туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан мәктәп тәҗрибә участогында авыл хуҗалыгы культураларын тирәнтен өйрәнү, аларны эшкәртүнең яңа технологияләре үзләштерелә башлый. Укучыларда тупланган белем һәм тәҗрибәне уртаклашу, үзара көч сынашу ниятеннән районда “Яшь авыл хезмәтчәннәре һәм табигатьне яратучылар” слеты үткәрелеп килә. Анда балалар “Яшь сөрүче”, “Яшь савымчы”, “Яшь урманчы”, “Зәңгәр патруль” , “Яшел патруль” секцияләренә бүленеп көч сынаша. Исәнбай мәктәбе командасы бу слетта берничә ел уңышлы чыгыш ясый, призлы урыннар ала (кушымта 12 ). Шушы ярышларда көч сынашкан балалар, үзләренең алдагы тормыш юлын авыл белән бәйләп, алдынгы хезмәт ияләре булып, хөкүмәтебезнең югары бүләкләренә лаек булдылар. ( кушымта 13).

“Тәрбия максаты – игелеклелек” девизы астында Исәнбай мәктәбе Лаеш балалар йорты белән дуслык урнаштыра. Бу эшне элеккеге пионервожатый, хәзер инде озынайтылган көн группасы тәрбиячесе Сундукова Гүзәлия башлап җибәрә. Группага йөрүчеләр башта балалар йорты белән хатлар алышсалар, соңрак “Шәфкатьлелек” ярминкәсе үткәреп, үзләре теккән-чиккән, бәйләгән әйберләрне сатудан кергән акчаны Лаеш балалар йортына җибәрәләр. Олы йөрәкле тәрбияче үткәргән ярминкәләр - ярдәмчеллек, кешелеклелек, шәфкатьлелек, изге күңеллелек дәресләре алар. Укучыларның башлангычы бүгенге көндә дә дәвам итә. Бу эшкә бөтен коллектив кушыла, Лаеш балалар йортына гына түгел, үзебезнең Әгерҗе шәһәрендә урнашкан “Наз” приютына да шәфкатьлелек акцияләре үткәрелә. [20]

Мәктәптә бу елларда да үз эшен, балаларны яратучы, милләтебезнең киләчәге өчен борчылып яшәүче тынгысыз мөгаллим һәм мөгаллимәләр эстафетасы лаеклы дәвам иттерелә. Мәктәп коллективы, укыту-тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү өчен, максатчан эш алып бара. Исәнбай мәктәбе районда үрнәк мәктәпләрдән санала, төрле фәннәр буенча семинарлар үткәрү гадәти күренешкә әйләнә, мәктәпне тәмамлаучыларның яртысыннан күбрәге укуларын югары уку йортларында дәвам итәләр.

Замана җилләре, илдә башланган үзгәртеп кору процессы, бер яктан караганда, Исәнбай мәктәбенә кагылмый кебек тоелса да, икенче яктан үзен бик нык сиздерә. Пионервожатый-инструктор Сундукова Г.З. истәлекләрендә әйтелгәнчә, "...әйе, гомерләр үтә тора, тормыш чишмәләре дә саега – тирәнәя, тирәнәя – саега ага да ага. Соңгы елларда әллә файдага, әллә зыянга шул тормыш чишмәләре буенда җемелдәгән пионер очкыннары да сүнеп бара...”

**3.5. Замана җилләренә бирешмичә.**

Ләкин замана үзгәрде дип, болгавыр чорда мәктәптә тәрбия эшенә кул селтәп булмый. Элекке идеаллар, карашлар юкка чыкты, әмма әле яңалары әзер түгел. Кемдер гаиләгә басым ясый, кемдер халык педагогикасына мөрәҗәгать итәргә куша, кемдер дин аша тәрбияләргә тырыша. Бар да хаклы, бар да дөрес, чөнки укыту- тәрбия мәсьәләсендә төгәл генә концепция юк.

Мәктәп коллективы алдында, базар икътисады шартларына яраклашып, мәктәбебезнең буыннан-буынга күчеп килгән традицияләрен дәвам итү бурычы тора. Базар экономикасы таләпләре яктылыгында радикаль үзгәрешләр бара. Педагоглар укыту-тәрбия процессын Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы” һәм “Телләр турындагы” Законнары нигезендә оештыралар. Катлаулы финанс-экономик шартларына карамастан, алар белем бирү системасын үстерәләр, балаларны өйрәтү-тәрбияләүнең яңа формаларын һәм методларын эзлиләр. Исәнбай укытучылары исә, тарихи традицияләргә тугры калып, халык педагогикасы үзенчәлекләрен саклап, балаларга ныклы белем бирүне дәвам итәләр. Барлык фәннәр буенча да белгеч- кадрлар туплауга аеруча басым ясала. 1992 нче уку елында мәктәбебезгә югары белемле музыка белгече Латыйпова Алсу Рафаиловна килә. Тынгысыз, сәләтле, һәрчак эзләнүчән яшь мөгаллимә балаларның музыкаль сәләтләрен үстерүгә бик нык әһәмият бирә һәм “Ләйсән” балалар җыр-бию ансамбле оештыра. Тиз арада бу ансамбль авылда гына түгел, район күләмендә дә танылырга өлгерә. “Яңарыш ” (1998, май) газетасында басылып чыккан мәкаләдә түбәндәге юллар бар:



*“ Мәктәбебездә төрле түгәрәкләр эшли. Дәрестән тыш вакытларыбызны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә тырышабыз. Мин биергә һәм җырларга яратам . Шуның өчен дә “Ләйсән” ансамбленә һәм хореография түгәрәгенә йөрим . Анда безне Алсу апа матур итеп җырларга һәм бию серләренә өйрәтә. Мәктәбебездә уздырылган кичәләрдә , бәйрәмнәрдә ул өйрәткән биюләр белән чыгыш ясыйбыз. Шулай ук авыл сәхнәсен дә читләтеп узмыйбыз. Авыл халкы биюләребезне яратып карый.”(Мозаффарова Л.)*

Шул ук елны мәктәптә эшли башлаган татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хуҗина Гөлназ Рәфисовна “Тамчылар” драма түгәрәге оештырып җибәрә. Укучылар куйган Р.Мингалимнең “Сандугач сары түгел”, Ә.Рәшитов “Бимбамбом”, Г.Исхакый “Кәҗүл читек”, “Алдым- бирдем” спектакльләрен авылдашлар җылы кабул итә. Шушы түгәрәк әгъзасы Гөлнур Йосыпова истәлекләре безгә балаларның түгәрәктә бик теләп шөгыльләнүен һәм авыл халкының спектакльләрне бик яратып каравы хакында сөйли: “*Без укытучыбыз Гөлназ апа Хуҗина җитәкләгән драма түгәрәгенә бик яратып йөрибез. Түгәрәкнең исеме дә җисеменә туры килә- “Тамчылар”. “Кунак кызы”, ”Өйрәттеләр”,*



*“Бимбамбом”, “Галиябану”- болар драма түгәрәге әгъзалары сәхнәләштергән әсәрләрнең кайберләре генә. Спектакльне залдан каравы гына рәхәт. Әсәрне тамашачы күңеленә хуш килерлек итеп сәхнәләштерү өчен бик күп көч, тырышлык куярга кирәк бит. Ә безнең драма түгәрәге артистлары, 7-8 класс укучылары гына булсалар да, үзләренә тапшырылган рольләрне оста башкаралар. Гөлназ апа безгә сәхнә серләрен өйрәтә. Иң зур кыенлык - декорация ясау һәм кием табу. Әмма без, төшенкелеккә бирелеп, кул кушырып утырмыйбыз. Барысын да үзебез ясарга тырышабыз. Кем белә, киләчәктә бәлки арабыздан чын артистлар да чыгар. Ә хәзергә әти-әниләр, әбиләр, авылдашлар безнең чыгышларны көтеп алалар һәм яратып карыйлар.”*

Чыннан да, Гөлнурның фаразлары тормышка аша. Түгәрәкнең элекке члены Бәдретдинов Ринат - бүгенге көндә Минзәлә Дәүләт драма театры артисты.



“Тамчылар” драма түгәрәге үз эшчәнлеген “Ләйсән” җыр-бию ансамбле белән берлектә оештыруы үзенчәлекле һәм отышлы күренеш була. Алар, бергәләп, төрле очрашулар, әдәби- музыкаль композицияләр әзерлиләр. 1996-1998 нче елларда “Ләйсән” ансамбле һәм “Тамчылар” драма түгәрәге оештыруында район күләмендә авылдашларыбыз язучы-шагыйрә Гөлзада Әхтәмова, балалар җырлары авторы Гөлсинә Гәрәева, райондаш язучыбыз Чыңгыз Мусиннарның иҗат кичәләре зур уңыш белән уза. Чаллы шәһәрендә нәшер ителүче “Көмеш кыңгырау” һәм Удмуртия Республикасында чыгып килүче “Яңарыш” газеталары белән очрашулар мәктәптә иҗади атмосфера тудыруга ярдәм итә. Мәктәп базасында үткәрелә торган бер генә район семинарлары да алар чыгышыннан башка узмый. Юл йөрү кагыйдәләренә багышланган “Тәмлетамак маҗаралары” исемле театральләштерелгән тамаша, район күләмендә җиңү яулап, Казан телевидениесеннән күрсәтелә.



Чыннан да, укучыларның буш вакытын оештыруга зур игътибар бирелә. 1996 нчы елда Исәнбай урта мәктәбе базасында милли көрәш һәм самбо түгәрәге оеша. Садыйков Рәшит Хәбибрахманович җитәкчелегендә 45 яшүсмер сәламәтлекләрен ныгыта һәм физик яктан чыныгу үтә. Физик тәрбия балаларда нык характер, саф әхлак сыйфатлары формалаштыра. Милли көрәш түгәрәге членнары район, зона спорт ярышларында, Сабантуйларда җиңүләр яулый. Республика ярышларында да үзләрен сынатмыйлар. Күп кенә укучыларыбыз – Нәгыймов Р., Шәрипов Р., Симаков Р., Сәйфетдинов М., Башаров Р. - Әлмәт педагогия техникумын тәмамлап, физкультура укытучылары булдылар.

Бер төркем укучылар исә, югары дини уку  йортын тәмамлап, имам- хатиб булып эшләүче, балалар күңеленә иман нурын иңдерүче Фәрит хәзрәт Җәмилев оештырган гарәп теле түгәрәгендә шөгыльләнәләр.

Мәктәп коллективы мәктәп үз йөзен булдырырга тиеш дигән позициядән чыгып эш итә һәм аның традицияләрен формалаштыру өстендә эшли. Дәреслә рдән соң тәрбия эшләре алып бару- балаларга төпле белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең бер өлеше. Класстан тыш эшләр балаларның белемен дә, зиһенен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт- мөмкинлекләренә уңай тәэсир итә торган итеп үткәрелә. “Белем бәйрәме”, “Соңгы кыңгырау”, “Туган тел” бәйрәме, “Гаилә бәйрәме”, “Сөмбелә”, Нәүрүз”, “Нардуган”, “Кошлар көне”, “Әлифба бәйрәме”, “Карга боткасы”, “Җиңү көне”бәйрәмнәре – ул безнең традицион бәйрәмнәребез.

Математика, физика, татар-рус-инглиз телләре, музыка, тарих, химия, биология, физкультура, тормыш иминлеге нигезләре буенча атналыклар, КВНнар, ярышлар, телевизион эш формаларына нигезләнгән уеннар, студентлар белән очрашу, әниләр бәйрәме мәктәбебездә Һәр елны үткәрелә торган кичәләрдән санала.

Укучылар өчен тагын бер зур яңалык –  1991 нче елда мәктәпкә БК0010 маркалы  компьютер кайта. Яшь белгеч Исмәгыйлева Ф.М. тиз арада үзлегеннән аның серләренә төшенә, компьютерда эшләргә өйрәнә һәм информатика дәресләре алып бара башлый. Ләкин компьютер берәү генә булу сәбәпле, анда һәр укучы да эшләү мөмкинлегенә ирешә алмый. Бу үзенә күрә балалар арасында ярыш формасын ала, һәрберсе алдынгы булырга теләп, компьютерны ныграк үзләштерергә омтыла. 1996 нчы елда мәктәптә яңартылган программалы  компьютер классы оештырылу белән укучылар алдында зур мөмкинлекләр ачыла. Ә 2001нче елда бу компьютерлар бөтен мөмкинлекләре булган яңа буын компьютерлар белән алышына. Ә 2006 нчы елдан мәктәп интернет челтәренә тоташтырыла.

Мәктәпнең зур юбилее 100 еллыгы якынлаша.. Бу тотрыксыз заманда юбилей үткәрүнең авырлыгын үз җилкәсенә төшкән кеше генә беләдер. Укытучылар, укучылар, авыл халкы бердәм булып, бәйрәмгә әзерлек эшләре башлыйлар. Иң беренче чиратта киң күләмле ремонт  эшләре үткәрелә. Элеккеге чыгарылыш укучылары, ветеран-педагоглар, күренекле шәхесләр белән элемтә урнаштырыла, хатлар алышу башлана, истәлекләр язып алына. Мәктәп тарихы тагын да җентекләп өйрәнелә, альбомнар, стендлар төзелә. Мәктәп коллективы юбилейга әзерлек көннәрендә мәгариф өлкәсендәге





булдыклыгын тагын бер кат дәлииллəп күрсәтә.

1997 нче елның 24 нче маенда юбилей бик күп авылдашларыбызның күңелендә җуелмаслык хатирәләр калдырып, тантаналы төстә, зур уңыш белән үтә. Казанда нәшер ителүче “Сөембикә” журналы хезмәткәре журналист-авылдашыбыз Зәлидә Әкберова истәлекләре дә моны тагын бер кат дәлилли.

“*Бу көнне май чәчәкләренә төренгән авыл үзе дә гаҗәеп матур бәйрәм тантанасына чумган. Табигать тә бәйрәмгә чалт аяз, кояшлы җәйге көн бүләк итте.*

*Таң белән Казан радиосы тапшырган “Исәнбай” җыры авылдашларга, мәктәп коллективына иң тәүге котлау булып яңгырады. Күп еллар элек Мостафа Ногман белән Сара Садыйкова безнең авылга багышлап язганнар иде аны. Шушы җыр мәктәп тантанасын ачып җибәрде.*

*Туган мәктәбебез үз карлыгачларын ачык йөз белән каршылады. Кайнар коймаклы чәй табыны янында күп буын укучылар, укытучылар очрашты.*

*Кунакларның мәктәп буенча сәяхәте укучылар иҗаты белән зәвыклы итеп бизәлгән коридор, класслардан башланды...*

*...Мәктәптә башланган бәйрәм болындагы сабантуй мәйданына күчте. Яшьлек елларын сагынып кайткан ветераннарның эчкерсез котлау сүзләре укучылар концерты белән аралашып барды.*

*Мәктәпнең драма түгәрәге һәм “Ләйсән” ансамбле тарафыннан әзерләнгән җыр-биюләр күңелләребезгә бик хуш килде.*

*Йөз ел эчендә мактаулы юл үткән мәктәп чәчкән күркәм орлыклар бүгенгәчә әнә шулай яңа шытым биреп үсәләр. Бу өлкән буын өчен дә, яшь буын өчен дә зур горурлык...*

*...Шушы юбилей уңаеннан, беренче укытучым Роза апа Гыймаева өйрәткән хәрефләрдән төзелгән “Зур Рәхмәт!”не Исәнбай мәктәбенең һәммә укучылары исеменнән барлык укытучыларына да җиткерәсе килә”.*

Гөрләп узган юбилей бәйрәмнәре укытучыларга яңа көч, яңа дәрт өсти. Мәктәп коллективы тагын да илһамланып, “Укыту-тәрбия процессын индивидуальләштерү һәм дифференциальләштерү” дигән проблема өстендә эшли башлый. Дәресләрнең күпчелеге югары фәнни дәрәҗәдә, аңлаешлы, тормыш һәм гамәли эш белән бәйләнешле, проблемалы булуы, яңалык алып килүе белән аерылып тора. Һәр дәрестә укыту-тәрбия бердәм процесс итеп карала.

Укучылар, район һәм республика күләмендәге олимпиада, конкурсларда катнашып, уңышларга ирешәләр.

1997 нче елдан район күләмендә укучыларда милли үзаң тәрбияләү һәм иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан “Көмеш каләм” район фестивале үткәрелә башлый. Бу мәктәп тарихында гына түгел, район тарихында зур бер яңа этап булып тора. Мәктәптә эшләп килүче “Тамчылар”драма түгәрәге үзенең эшчәнлеген әдәби-иҗат түгәрәге буларак алып бара башлый. Аларның иҗат җимешләре “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Ялкын”, “Яңарыш”, “Әгерҗе хәбәрләре” газеталары битләрендә даими басылып килә. Бу түгәрәккә йөрүчеләр фестивальнең төрле номинацияләрендә һәр ел саен бары тик призлы

урыннар гына яулыйлар.  2007 нче елда ике укучы- Латыйпова М. һәм Садыйкова Э. 12нче балалар һәм яшьләр матбугатының зона фестивалендә җиңеп, Б. Полевой теплоходында республика яшьләре арасында көч сынашалар. Нәтиҗәләрне түбәндәге таблицадан күреп була.

“Көмеш каләм” –район иҗат фестивале нәтиҗәләре

| | |
|---|---|
| 1997 | Җәмилева Лениза (“Поэзия”) - I урын |
| 1998 | II урын- Йосыпова Г.(”Яшь хәбәрче”);<br>II урын -“Тамчылар” әдәби-иҗат  берләшмәсе |
| 1999 | II урын- Бәдретдинова Г. (“Яшь хәбәрче”) ;<br>III урын- Мухъянова Алсинә (“Проза”) |
| 2000 | II урын- иҗат күргәзмәсе,<br>Бәдретдинова Г.— “Иң актив яшь хәбәрче” |
| 2003 | I урын- Латыйпова М. (“Поэзия”)<br>III  урын-  Тукманова Л. (“Проза”),<br>III урын- Борһаниев И. (“Яшь хәбәрче”)<br>Хуҗин Р., Мозаффарова Л.-“Иң  актив яшь хәбәрче” |
| 2004 | I урын- “Тамчылар” әдәби-иҗат берләшмәсе;<br>I урын-  газета ”Тамчылар”;<br>Латыйпова М. ,  Хуҗин Р.-“ Иң актив яшь хәбәрче” |
| 2005 | I урын-“Тамчылар” әдәби-иҗат  берләшмәсе;<br>I урын- газета ”Тамчылар”;<br>II урын- Мозаффарова Л.- ( “Яшь хәбәрче”);<br>Латыйпова М., Садыйкова Э., Әхмәдеева А., Ханнанова А..-“Иң актив яшь хәбәрче” |
| 2006 | I урын -“Тамчылар”әдәби-иҗат  берләшмәсе<br>III урын - газета  ”Тамчылар”;<br>V урын - Мозаффарова Л.- ( Яшь хәбәрче); Әхмәдеева А.,(проза)<br>ЛатыйповаМ., ӘхмәдееваА., Сабитов Р., Ханнанова А.-“Иң актив яшь хәбәрче” |
| 2007 | I урын-“Тамчылар” әдәби-иҗат берләшмәсе<br>I урын- Латыпова М (“Проза” )<br>I урын-Әхмәдеева А (“Поэзия”)<br>IVурын –Хуҗин Р (“Сәнгатьле уку”)<br>Латыйпова М., Хуҗин И., Кәримова Г.- “Иң актив хәбәрче”<br>Латыйпова М, Садыкова Э – “Алтын каләм” зона, республика конкурслары лауреатлары |

Ә инде фестивальнең 10 еллык юбилеен Исәнбай мәктәбендә үткәрү очраклы хәл генә түгел, ә бәлки шуны түгәрәк эшчәнлегенә югары бәя бирү дә.

Фестиваль бәйрәм төсен ала. Ул күрше Удмуртия һәм Татарстан республикасында яшәүче иҗат сөючеләрне үзенә җыя. Укучыларның фикерләре дә фестивальнең зур көчкә ия булганлыгын раслый.

*Ләйсирә Музаффарова: "Фестиваль үз көчеңне сынарга мөмкинлек бирә, ышаныч өсти. Мин быел мәктәпне тәмамлыйм. Хыялым – журналист булу. "Көмеш каләм", синдә канат ярдым, ныгыдым, зур тормышка юл алдым, рәхмәт сиңа!"*

*Миләүшә Латыйпова: "Көмеш каләм"- минем өчен гади фестиваль генә түгел, ә безнең татар икәнебезне, рәхәтләнеп татар телебездә иҗат итә белүебезне күрсәтә торган бәйрәм."*

*Энҗе Садыйкова: "Көмеш каләм" бар нәрсәне онытып, хыял диңгезенә чумарга, энҗе-мәрҗәннәр эзләргә, табарга зур мөмкинлекләр ача. Үзеңә иҗади хискә бай, мөлаем дуслар табарга ярдәм итә."*

*Ләйсән Борһаниева: "Көмеш каләм" – зур бәйрәм. Ул кеше күңелендә матур хисләр уята, иҗат аша кешелеккә үз фикереңне җиткерергә өйрәтә. Курыкмагыз! Иҗат итегез! Үз сүзегезне әйтегез!"*

*Айгөл Әхмәдиева: "Көмеш каләм"- минем өчен зур тантана. Ул яшьләрне иҗатка тарта, шул ук вакытта таныштыра да, дуслаштыра да. Кыскасы, "Көмеш каләм" – сөенеч, дәрт, илһам чыганагы ул!"*

1998 нче елдан укучыларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгыту зур басым ясала. Шул ук елны безнең мәктәптә дә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Садыйкова Г.З. Һәм ТИН укытучысы Зәйнуллина Г.З.-лар җитәкчелегендә укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча программа төзелә. Бу программа тәрбия системасының иң мөһим юнәлешләренең берсе була. Шуның нигезендә һәр укучының сәламәтлек паспорты төзелә. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: бу эш хәзерге көнгә кадәр алып барыла. Сәламәт тормыш рәвеше күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән спорт- сәламәтләндерү көннәре, "Тормыш куркынычсызлыгы нигезләре" атналыгы, мәктәп олимпия уеннары , хәрби- патриотик айлыклар үткәрү традициягә әйләнә. Наркомания, тәмәке тартуга һәм алкоголизмга каршы күп кенә чаралар, системалы төс алып, хәзерге көнгә кадәр нәтиҗәле эшләп килә.

1999-2000 нче уку елында мәктәбебез лаеклы хезмәте өчен "Ел мәктәбе-2000" район конкурсында I урын ала һәм диплом белән бүләкләнә, "Бронза дәрәҗәсенә ия булган сәламәтлекне саклау мәктәбе " дигән квалификацион характерстика бирелә.(кушымта 14, 15) Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгытуда тупланган тәҗрибә белән уртаклашу максатыннан район, республика күләмендә күргәзмәләр, семинарлар оештыра.

Мәктәп коллективының укыту-тәрбия өлкәсендәге "Укытуны индивидуальләштерү һәм дифференциальләштерү аша укучыларның иҗади активлыгын үстерү" проблемасы буенча эше район мәгариф бүлеге тарафыннан югары бәяләнә, мактау грамотасы белән бүләкләнә. (кушымта 16)

Укыту-тәрбия процессын камилләштерүдә заманча технологияләр куллану - иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. Шуны истә тотып, Исәнбай мәктәбе

укытучылары дәресләрнең төрле этапларында интернет, компьютер технологияләре кулланып эшлиләр. Исәнбайлыларның эш тәҗрибәсе “Заманча мәгълүмати технологияләр үсеше шартларында укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү” дигән темага багышланган район семинарларын гомумиләштерелә.

Мәгарифне модернизацияләү этабында белем сыйфатын күтәрү һәм конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү проблемасы - көн кадагы мәсьәләсе ул. Сәләтле укучылар белән эшләүгә аеруча басым ясала. Укучылар төрле олимпиадаларда, конкурсларда югары нәтиҗәләргә ирешәләр, фәнни-практик конференцияләрдә чыгыш ясыйлар, фәнни-эзләнү эшләренә тартылалар. Мәктәптә сәләтле укучыларның банкы булдырыла. Бирелгән таблицада без бу уңышларны ачык күрәбез.

Укучыларның конкурсларда, олимпиадаларда ирешкән уңышлары
2004-2005 нче уку елы
Республика дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Музафарова Ләйсирә<br>Мөлекова Алия<br>Ханнанова Илнара | II дәрәҗә<br>Диплом<br><br>II дәрәҗә<br>Диплом | Бөек Җиңүнең 60 еллыгына багышланган “Онытмыйча яшик” экскурсияләр конкурсы<br>Казанның 1000-еллыгына багышланган “Үз тормышларын Казан белән бәйләгән авылдашларым язмышы” экскурсияләр конкурсы |
| 2. | Латыйпова Айгөл<br>Латыйпов Вәсил<br>Ризванова Гөлнур<br>Галимуллина Лилия<br>Зәйнуллина Айсылу<br>Садыкова Энҗе<br>Вәлиев Айдар<br>Хәбиров Раил<br>Латыйпова Миләүшә<br>Саликова Лилия<br>Садыйкова Гөлназ<br>Саликов Рамил<br>Кәримова Гүзәл<br>Хуҗин Илшат<br>Сундуков Марат<br>Сундуков Әлфир<br>Шәрипов Илнур | Мактау кәгазьләре | “Сабантуй” газетасы оештырган “Балачак” рәсемнәр конкурсы |
| 3. | Сабитов Ринас | 3 урын | “Көмеш кыңгырау газетасы оештырган “Машина йөртүчегә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ачык хат” иҗат конкурсы |
| 4. | Латыйпова Миләүшә | Рәхмәт кәгазе | “Яңарыш” газетасының актив хәбәрчесе |

Район дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс,олимпиада исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Мухъянова Алия | 2<br>3 | Татар әдәбияты,<br>хокук белемнәре буенча олимпиада |
| 2. | Музафарова Ләйсирә | 3<br>3 | Татар теле,<br>рус әдәбияты буенча олимпиада |
| 3. | Ханнанова Алинә | 3 | Татар әдәбияты буенча олимпиада |
| 4. | Хисматуллина Алсу | 1 | Математика буенча олимпиада |
| 5. | Латыйпова Айгөл | 2 | Рус теле буенча олимпиада |
| 6. | Латыйпова Миләүшә | 1<br><br><br><br>2<br><br>1 | Бөек Җиңүнең 60 еллыгына багышланган “Бөек Ватан сугышында гаиләм тарихы” иҗат эшләре конкурсы<br>“Куркынычсыз тәгәрмәч” конкурсы<br>“Көмеш каләм” фестивале<br>“Иң яхшы” газета номинациясе |
| 7. | Мухъянова Алия | 3 | “Сугыш чорлары поэзиясе” сочинениеләре конкурсы |
| 8. | Музафарова Ләйсирә<br>Мөлекова Алия<br>Садыйкова Энҗе | 2<br>2<br>3 | Казанның 1000 еллыгына багышланган “Мин сезгә язам” иҗат эшләре конкурсы |
| 9. | Вәлиев Айдар<br>Тукманов Данир<br>Садыйкова Энҗе | 3<br>Рәхмәт кәгазе<br>Рәхмәт кәгазе | “Ут – кешенең дусты һәм дошманы” рәсем конкурсы |

2005-2006 нчы уку елы

Регионара дәрәҗә:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс, олимпиада исеме |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Әхмәдиева Айгөл | Рәхмәт кәгазе<br><br>1 | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада;<br>“Яңарыш” газетасы оештырган Казанның 1000 еллыгына багышланган иҗат конкурсы |
| 2. | Хисматуллина Алсу | 3 | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада; |
| 3. | Нурмөхәмәтов Динис | 2 | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада; |
| 4. | Низамова Гүзәл | Рәхмәт кәгазе | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада; |
| 5. | Сабитов Альмир | 3 | М.Җәлилнең тууының 100 еллыгына багышланган милли көрәш бәйгесе |

Республика дәрәҗәсе

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Латыйпова Миләүшә | 7<br><br>таныклык | Татар әдәбияты буенча олимпиада;<br>“Көмеш кыңгырау”, “Яңарыш”, ”Әгерҗе хәбәрләре” газеталарының актив корреспонденты |
| 2. | Борһаниева Ләйсән | 2 | “Татарстан яшьләре” газетасы оештырган “Бәрәңгегә Һәйкәл” иҗат конкурсы |
| 3. | Әхмәдиева Айгөл | 2<br><br><br><br>таныклык | “Сабантуй” газетасы оештырган “Тукайлар, Җәлиләр дәвамы” иҗат конкурсы;<br>“Көмеш кыңгырау”, “Яңарыш”, ”Әгерҗе хәбәрләре” газеталарының актив хәбәрчесе |
| 4. | Хуҗин Рөстәм | 1<br><br><br>2 | “Тәрбия” газетасы оештырган “Син Җәлилне беләсеңме?” конкурс-викторинасы;<br>“Сабантуй” газетасының “Хәерле юл” кушымтасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | оештырган конкурс- викторина |
| 5. | Хәбиров Раил | 3 | “Сабантуй” газетасының “Хәерле юл” кушымтасы оештырган конкурс- викторина |
| 6. | Музафарова Ләйсирә | таныклык | “Көмеш кыңгырау”, “Яңарыш”, ”Әгерҗе хәбәрләре” газеталарының актив хәбәрчесе |

Район дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Хисматуллина Ләйлә | 1<br>2 | Математика буенча олимпиада,<br>“Куркынычсыз тәгәрмәч” |
| 2. | Латыйпова Миләүшә | 2<br>2<br>2 | Татар әдәбияты,<br>рус әдәбияты,<br>рус теле буенча олимпиада |
| 3. | Җәмилева Нурия | 1 | татар теле буенча олимпиада |
| 4. | Әхмәдиева Айгөл | 2 | ТИН буенча олимпиада |
| 5. | Музафарова Ләйсирә | 2 | татар теле буенча олимпиада |
| 6. | Садыкова Энҗе<br>Музафарова Ләйсирә<br>Латыйпова Миләүшә | 1<br>1<br>1 | Фестиваль “Йолдызлык-2006” |
| 7. | Музафарова Ләйсирә<br>Сундукова Регина | 1<br>Рәхмәт хаты | Толстой исемендәге фәнни-практик конференция |
| 8. | Сабитов Альмир<br>Шарафиев Альмир<br>Гобәйдуллин Илназ<br>Хабиров Ранис<br>Галимуллин Айнур<br>Мөэминов Рәдиф<br>Гобәйдуллин Рузил<br>Мөхәммәдиев Рәзил<br>Сабитов Ринас<br>Фәтхетдинов Эльмир<br>Сираев Рөстәм | 1<br>1,2<br>1,2<br>1,2<br>1,2<br>1,2,3<br>1,3<br>2,3<br>2,3<br>1,2<br>2,3 | Милли көрәш бәйгеләре |

2006-2007 нче уку елы

Регионара дәрәҗә:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Латыйпов Вәсил | бонус | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада |
| 2. | Хисматуллина Ләйлә | бонус | Математика буенча “Авангард” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мәктәбе оештырган олимпиада |

Республика дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | “Туган якны өйрәнү” түгәрәге | 2<br><br><br><br>3 | “Мәгариф” журналы оештырган Алабуганың 1000 еллыгына багышланган конкурс-викторина (1тур)<br>2тур |
| 2. | “Тамчылар” түгәрәге | 1 | “Көмеш кыңгарау” газетасы оештырган “Чишмәләргә юлны онытма” иҗат конкурсы |
| 3. | Латыйпова Айгөл | 2 | “Космос-2007” рәсем конкурсы |
| 4. | Әхмәдиева Айгөл | 6<br><br>Мактау грамотасы | татар әдәбияты буенча олимпиада<br>К.Насыйри исемендәге фәнни-практик конференция; |
| 5. | Садыйкова Энҗе | 2<br><br><br>3 | “Алтын каләм” XII зона иҗат фестивале, номинация “Иң яхшы телетапшыру;<br>Номинация “Татар телендә иң яхшы мәкалә” |
| 6. | Латыйпова Миләүшә | 2 | “Алтын каләм” XII зона иҗат фестивале, номинация “Иң яхшы телетапшыру; |

Район дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Әхмәдиева Айгөл | 1<br>2 | Татар әдәбияты,<br>җәмгыять белеме буенча олимпиада |
| 2. | Хисматуллина Алсу | 2<br>2<br>3 | Татар теле,<br>математика,<br>рус әдәбиятыннан олимпиада |
| 3. | Җәмилева Нурия | 2 | Татар теле буенча олимпиада |
| 4. | Низамова Гүзәл | 2<br>2<br>2 | Татар теле,<br>рус теле,<br>математика буенча олимпиада |
| 5. | Зарифуллина Айгөл<br>Садыйкова Гөлназ<br>Зәйнуллина Айсылу<br>Латыйпов Вәсил | 1<br>4<br>3<br>1 | Математик уен-конкурс “Көнгерә” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гильфанов Нияз<br>Мухъянова Гүзәл<br>Латыйпова Айгөл<br>Кәримова Гүзәл<br>Хисматуллина Ләйлә<br>Ханнанова Алисә<br>Зарипов Марат<br>Рамазанов Альмир<br>Садыйкова Энҗе | 2<br>6<br>1<br>3<br>1<br>3<br>2<br>6<br>4 | |
| 6. | Латыйпова Айгөл<br>Латыйпов Вәсил<br>Ризванова Гөлнур<br>“Тамчылар” түгәрәге | Мактау кәгазьләре | “Марш парков – 2007” |
| 7. | Нурмөхәмәтов Динис | 3 | Д.С.Лихачевның 100 ел тулу уңаеннан уздырылган рефератлар конкурсы |
| 8. | Әхмәдиева Айгөл | 3 | К.Насыйри исемендәге фәнни-практик конференция |
| 9. | Нурмөхәмәтов Динис<br>Хуҗин Рөстәм<br>Садыйкова Энҗе<br>Латыйпова Миләүшә<br>Тукманов Нияз | 2<br>2<br>2<br>2<br>Мактау кәгазе | Фестиваль “Йолдызлык-2007” |
| 10. | Латыйпов Вәсил<br>Латыйпова Миләүшә<br>Шәрипов Дамир<br>Садыйкова Энҗе | 3<br>Мактау кәгазе<br>Мактау кәгазе<br>Мактау кәгазе | “Яшь программист” конкурсы |
| 11. | Латыпова Миләүшә<br>Әхмәдиева Айгөл | 1<br>1 | “Көмеш каләм” иҗат фестивале |
| 12. | Сабитов Альмир<br>Шарафиев Альмир<br>Гобәйдуллин Илназ<br>Хабиров Ранис<br>Галимуллин Айнур<br>Мөэминов Рәдиф<br>Гобәйдуллин Рузил<br>Мөхәммәдиев Рәзил<br>Сабитов Ринас<br>Фәтхетдинов Эльмир<br>Сираев Рөстәм | 1<br>1,2<br>1,2<br>1,2<br>1,2<br>1,2,3<br>1,3<br>2,3<br>2,3<br>1,2<br>2,3 | Милли көрәш бәйгеләре |
| 13. | Хасанова Розалина<br>Шәрипов Дамир | Мактау кәгазе | Лобачевский исемендәге фәнни-практик конференция |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Мукашева Лилия<br>Саликова Лилия<br>Низамбиева Айгөл<br>Борһаниева Ләйсән<br>Садыйкова Энҗе | | |
| 14. | Латыйпова Айгөл | 2 | “Куркынычсыз хәрәкәт - һәлакәтсез тормыш” иҗат конкурсы |
| 15. | Мухъянова Гүзәл<br>Латыйпов Вәсил<br>Зәйнуллина Айсылу | 3<br>3<br>3 | “Куркынычсыз тәгәрмәч” конкурсы |

2007-2008 нче уку елы
Россия дәрәҗәсендә;

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Садыкова Энҗе | Зиминнар гранты<br>Мактау кәгазе<br>Махсус диплом | Сәләтле балаларның Интел Династия Авангард дәүләтара фәнни- практик конференциясе |

Регионара:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Хуҗин Илшат | 1 | “Яңарыш” газетасы оештырган “Яшь әкиятче” иҗат бәйгесе |
| 2. | Латыйпова Айгөл<br>Хәбиров Ранис<br>Кәримова Гүзәл<br>Нәгыймова Анастасия | 1 | “Яңарыш” газетасы оештырган “Минем Кыш бабай белән беренче очрашуым” иҗат бәйгесе |
| 3. | Латыйпова Айгөл | 2 | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада |
| 4. | Латыйпов Вәсил | 2 | Математика буенча “Авангард” мәктәбе оештырган олимпиада |

Республика дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Хуҗин Рөстәм | 2<br><br>Мактау кәгазе | Милиция көненә багышланган сочинениеләр конкурсы<br>“Мин – тикшерүче” фәнни-практик конференциясе |
| 2. | Хисматуллина | II дәрәҗәдәге | “Мин – тикшерүче” фәнни- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Ләйлә | диплом<br><br>Мактау кәгазе<br><br>Мактау кәгазе | практик конференциясе<br>Яшүсмерләрнең К.Насыйри исемендәге фәнни- тикшеренү конференциясе<br>Г.Исхакыйның юбилее уңаеннан оештырылган “Онытылмас мирас” конкурс-викторинасы |
| 3. | Латыйпова Миләүшә | I дәрәҗәдәге диплом | Яшүсмерләрнең К.Насыйри исемендәге фәнни- тикшеренү конференциясе |
| 4. | Ханнанова Алисә | II дәрәҗәдәге диплом | “Мин – тикшерүче” фәнни-практик конференциясе |
| 5. | Җәмилева Нурия | 2<br><br><br>Мактау кәгазе | “Мәгариф” журналы оештырган «Кем зирәгрәк?» экологик конкурс-викторинасы,<br>Яшүсмерләрнең К.Насыйри исемендәге фәнни- тикшеренү конференциясе |
| 6. | “Туган якны өйрәнү” түгәрәге | 6 | “Мәгариф” журналы оештырган “Яшь тарихчылар” конкурс-викторинасы |

Район дәрәҗәсе:

| № | Укучының фамилиясе, исеме | урыны | Конкурс, олимпиада исеме |
|---|---|---|---|
| 1. | Латыйпова Миләүшә | 1<br>1<br>1 | Эшмәкәрлек нигезләре,<br>рус әдәбияты,<br>татар әдәбияты буенча олимпиада |
| 2. | Җәмилева Нурия | 2 | Татар теленнән олимпиада |
| 3. | Нурмөхәмәтов Динис | 1<br>2<br>3 | Татар теле,<br>рус әдәбияты,<br>технология буенча олимпиада |
| 4. | Садыкова Энҗе | 3 | Җәмгыять белеменнән олимпиада |
| 5. | Хабиров Раил | 2 | Татар теленнән олимпиада |
| 6. | Шәрипова Рәфилә | 1<br>2 | Математика,<br>татар әдәбиятыннан олимпиада |
| 7. | Хуҗин Рөстәм | 3 | Хокук белеменнән олимпиада |
| 8. | Мукашева Лилия | 2 | Татар әдәбиятыннан олимпиада |
| 9. | Симаков Нияз<br>Гильфанова Сөмбел<br>Тукманов Нияз<br>Хакимова Айгөл | Мактау кәгазьләре | «Русский медвежонок» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Рахматуллина Альмира<br>Зарифуллина Айгөл<br>Латыйпов Вәсил<br>Гильфанов Нияз<br>Мухъянова Гүзәл<br>Зәйнуллина Айсылу<br>Латыйпова Айгөл<br>Кәримова Гүзәл<br>Хисматуллина Ләйлә<br>Ханнанова Алисә | | |
| 10. | Кәримова Гүзәл<br>Мөэминов Рәдиф | 3<br>2 | Полиатлон буенча бәйге |
| 11. | Шарафиев А.<br>Губайдуллин Р.<br>Сабитов Р.<br>Хузин Р.<br>Сабитов А.<br>Галимуллин А.,<br>Мукминов Р.<br>Хуҗин И. | 1<br>2<br>2<br>2<br>2<br>3<br>1<br>2 | Милли көрәш бәйгесе |

Укучыларны олимпиадаларга әзерләү һәм сәләтле балалар белән эш оештыруда нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Исәнбай урта мәктәбе коллективы район мәгариф бүлеге тарафыннан мактау грамотасы белән бүләкләнә. [17]

2001-2008 нче елларда мәктәп “Мәгълүмати технологияләр үсеше шартларында укучыларда мөстәкыйльлек тәрбияләү” һәм “Профильле укытуга күчү шартларында укучыларның интелектуаль сәләтләрен үстерү , эзләнү күнекмәләрен формалаштыру һәм конкурентлыкка сәләтле шәхсе тәрбияләү” проблемалары өстендә эшли. Белемнең эффектлылыгын күтәрүдә перспектив юнәлешләрнең берсе булып, профильле укытуга күчү тора. 2006-2007 нче уку елыннан мәктәп информацион- технологик юнәлештә эшли башлый. Укытучылар тарафыннан 9 класста сайлап алу- “К.Насыйри , Р. Фәхретдин мирасы һәм татар дөньясы”(Хуҗина Г.Р.), “Математиканың сайланма сораулары”(Маннанова З.Г.); 10-11 классларда электив курслар программалары - “Подготовка тракторов в 10 классе к автоматизированному механическому труду” ( Симаков Ф.Ф), “XX йөз башы татар әдәбияты” (Хуҗина Г.Р.), “Нестандартные задачи материалов ЕГЭ по физике” (Исмагилова Ф.М.), “Обратные круговые функции” (Маннанова З.Г.), “Подготовка к ЕГЭ по русскому языку” (Сундукова Э.К.) - төзелә.

Нәкъ шушы ук елда информатика кабинеты “Иң яхшы информатика кабинеты” компьютер призентацияләре район конкурсында 1нче урынга лаек була. Профильле класста укучыларның белем сыйфаты сизелерлек арта. Моны

БДИ нәтиҗәләре дә раслый. 2007-2008 нче уку елында безнең мәктәп БДИны иң яхшы бирүче мәктәпләр исемлегенә кертелә. Шунысы куанычлы, 2007-2008 нче уку елында барлык укучылар да БДИны уңышлы тапшырып, район күләмендә иң югары күрсәткечләргә ирешәләр. Барлык чыгарылыш укучылары да алга таба укуларын югары уку йортларында дәвам итәләр. Шуларның икесе Латыйпова М. һәм Садыйкова Э. мәктәп тарихында беренче тапкыр урта мәктәпне көмеш медальгә тәмамлыйлар.

Мәгариф өлкәсендә эзлекле үзгәрешләр барган хәзерге чорда сыйфатлы белем бирү һәр укытучының бурычы ул. Заман безнең алга тагын да катлаулырак, колачлырак бурычлар куя. Хәзер тирән мәгълүматлы, белемле генә булу җитми, ә бәлки белемне гамәли эшчәнлектә тулысынча куллана белергә дә кирәк. Боларның барысы да безгә зур җаваплылык йөкли. Мондый шартларда югары квалификацияле кадрларның әһәмияте тагын да арта.

Мәктәп белән 2004 нче елдан Исмәгыйлева Ф.М. идарә итә. Исәнбай урта мәктәбендә бүгенге көндә 19 педагогик хезмәткәр эшли. Шуларның 18е -югары, 1се –махсус урта белемле. 1 укытучы - югары, 10 укытучы -1нче квалификацион, 5 укытучы – 2 нче квалификацион категориягә ия. БорҺаниева Ә. Т. РФнең “Мәгариф өлкәсендә уңышлары өчен”, Маннанова З. Г. ТРның “Мәгариф өлкәсендә уңышлары өчен” - күкрәк билгесе ияләре. Хуҗина Г. Р., Зайнуллина Г.З. лар ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Һәр педагогның үз иҗади карашлары, үз эш алымнары, үз йөзе булганга күрә, мәктәп заманча кызыклы тормыш белән яши, үсә, яңара, уңышларга ирешә.

## Йомгаклау

Мәктәбебезнең тарихын өйрәнеп, эзләнеп чыкканнан соң, күңелебездзге зур горурлык һәм хөрмәт хисләре тагын да көчлерәк яна башлады. Укытучы. Мәктәп. Кайсы гына чорны алсак та, бу ике сүз бер-берсеннән аерылгысыз, гел янәшә яшиләр.

Башлангыч мәктәп төзелү чоры... Авылыбызгы белем орлыклары чәчәргә милләтебезнең зыялы шәхесләре – Насыйбуллин Хәбибулла һәм аның хатыны Мөкәррәмә, Абдуллин Солтангазиз һәм хатыны Шәмсекамәрләр киләләр. Алар – беренче карлыгыачлар, мәктәпкә нигез салучылар. Сездәй олуг затлар белән ничек горурланмыйсың инде!

Наданлыкны бетерү өстендә, алны-ялны белмичә, бар көчләрен, тырышлыкларын куеп эшләгән, бер класста иллешәр бала укыткан, хөрмәтле фидакарь җанлы укытучыларыбыз алдында баш иябез.(кушымта 17)

Бөек Ватан сугышы чоры – мәктәп тарихында гына түгел, бәлки ил тарихында укытучыларны да, укучыларны да яңа яктан – хәтта ышанырга да авыр булган көчле рухлылык ягыннан ачкан чор. Тыныч кына, күз яшьләренә чыланмыйча гына, эшебезне алып бару бик авыр булды. Нинди көчле безнең халык: физик яктан да, барыннан да бигрәк рухи яктан! Сезнең алда бүгенге буын кешеләре мәңгегә бурычлы.

Әйе, укытучы эше беркайчан да җиңел булмаган. Гомер буе мәктәбебез алдынгылар рәтендә йөрде, йөри һәм йөриячәк.

Исәнбай мәктәбе күп еллар дәвамында илгә лаеклы күренекле шәхесләр әзерләп һәм тәрбияләп бирде. Без хаклы рәвештә алар белән горурланабыз.

Исәнбай авылының үз мәгърифәтчесе Хафизетдин Корбангалин була. Алар династиясе авылда иң зыялы нәселләрнең берсе санала. Фән кандидатлары Рәшидә Корбангалина, Фәридә Корбангалина, Исәнбай тарихын мәңгеләштерүдә үзеннән зур өлеш керткән Ниязи Корбангалин, Татарстанның атказанган врачы Эльза Ижболдина, балалар табибы Роза Ижболдина , агроном Азат Ижболдин - шушы нәселнең дәвамчылары.

Мәктәбебездә белем алып, фән кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән Шамил Җәмилев, Разия Хасанова, Хәмит Ризванов, доцент Рабига Ситдикова, биология фәннәре докторы Фәрит Ситдиков авылдашларыбыз горурлыгы.

Татарстанның атказанган врачы Ләйлә Кадыйрова, Россиянең сәламәтлек саклау отличниклары Рәшидә Борисова, Галия Борһаниева, врачлар Һ.Г Тукманов, Ә.Ф.Гарифуллина, Ә.Г. Шәмсетдинова, Н.Ризванов мәктәбебездә белем алган кешеләр.

Иҗади эшләп, эзләнеп, кешелек, әдәплелек башка күп күркәм сыйфатлар тәрбияләүгә үзләренең талантларын багышлаган “СССР мәгариф отличнигы” һәм Халыклар Дуслыгы ордены кавалеры Ф.М.Ахунҗанова, РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы Х.Г.Рахматуллин, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы Г.Р.Шәймарданова, Р.К.Ижболдин, Ф.Н.Зарипова, ТР ның “Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен” күкрәк билгесе белән бүләкләнгән укытучы Ф.М. Җәмилева, Мәгариф отличниклары А.Г.Ризванова, Әгерҗе район мәгариф бүлегенең методик үзәге мөдире А.Р.Муллахмәтова, укытучы-шагыйрә Ф.С.Тютиева-Нәҗмиева, укытучы-шагыйрә берничә китап авторы Г.Х.Әхтәмова-Ягъфәрова, шагыйрь Раил Шакиров, Әлфирә Низамова, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ф.Н.Сабитова, балалар җырлары авторы Г.Г.Гәрәева, ”Сөембикә” журналының хатлар бүлеге мөдире, журналист З.С.Әкбәрова-Фәйзуллина, Чаллы педагогия институтының тел-әдәбият укытучысы Л.К.Гализуллина, Ижау авыл хуҗалыгы институты проректоры булып эшләгән М.Н.Сабитов һәм башка бик күп күренекле авылдашларыбыз Исәнбай мәктәбенең данын тагын да күтәрәләр.

Россиянең сәүдә отличнигы Х.Ш.Исмәгыйлов, Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре Р.М.Вахитова-Зиннәтуллиналар да безнең мәктәптә белем алган укучылар.

Җир кешесе - намуслы, хисле, әхлаклы кеше ул. Шундый күркәм сыйфатларга ия булган орденлы авылдашларыбыз: С.Ф.Тютиев, Р.Җ. Борһаниева, К.А.Мөлеков, Н.И. Хәкимов, Р.Ш. Зарипов, Ф.Х. Сунлуков, И.Х. Ямалиев, Ф.Г. Хафизов, М.Н. Нәҗметдинова, Г.Г. Ягъфарова, Һ.Н. Ваһапова, Р.А. Насыйбуллина, Г.К. Ижболдина, Ә.З. Шәрәфиев, Ф.Н. Латыйповлар яшь буын өчен хезмәтне ярату, фидакарлек үрнәге булып торалар. Бу шәхесләр - укытучыларыбыз хезмәтенә мәңгелек һәйкәл.

Ләкин бүгенге көндә ил күләмендә укытучының дәрәҗәсе төшү безне бик борчый. Әйтерсең лә үткәннән укытучылар безгә: “ Акылыгызга килегез, кешеләр! Дөньяның тоткасы – гыйлемдә. Гыйлем бирүчеләрнең дәрәҗәсен

югары тотыгыз!” – дип дәшәләр. Чыннан да, бүгенге көндә инициативалы, энергияле, фидакарь җаннар, фанатиклар гына мәктәптә эшли ала.

## Кулланылган әдәбият


**I. Язма чыганаклар**

1. Бөек Ватан сугышы вакыты елларында Исәнбай урта мәктәбе (хатирәләр җыентыгы) -Исәнбай, 1947
2. Башаров Гаскәр. Класстан тыш эшләр турында. - Исәнбай, 1971
3. Гыймаева Роза. Пионер оешмасы.-Исәнбай, 2002.
4. Зарипова Фәтхия. Онытылмас еллар .-Исәнбай, 2002
5. Ижболдин Касыйм. Табаров оешмасы .-Исәнбай, 1997
6. Исмәгыйлева Лилия.Сугыш еллары балалары (язма хатирәләр) – Исәнбай,2004
7. Корбангалин Ниязи. Башлангач мәктәп тарихы. - Исәнбай, 1971
8. Кызыл эзтабарлар көндәлеге. - Исәнбай мәктәбе, 1970
9. Танаева Рубина. Пионер елларында.- Исәнбай, 2002
10. Телеграмма “Иптәш Сталинга”... -“Колхоз ярышы” газетасы. 1944, 9 июль
11. Телеграмма из Москвы №73/292, 31 мая 1944
12. Төхвәтуллин Исмәгыйль. Пионер оешмасы.-Исәнбай, 199

**II. Телдән чыганаклар.**

13. Ахунҗанова Фәридә хатирәләре
14. Борисова Кәүсәрия хатирәләре
15. Сундукова Гүзәлия хатирәләре.
16. Тютиев Сәгыйть хатирәләре
17. Хәкимова Асия хатирәләре
18. Хәкимов Назыйф хатирәләре

**III. Әдәбият**

19. Байсарлы В. Исәнбай,-Мәйдан, 2008, № 6.
20. Исмәгыйлова Г. Тәрбия максаты- игелеклелек.-“Җиңү юлы”, 1990, 9 октябрь.
21. Малкин И.И., Носов С.С., Яруллин Ш.К. Марш пионерии Татарстана- Казань, Татарское книжное издательство, 1970
22. Сабирова Д.К., Шәрәпов Я.Ш., Ватаныбыз тарихы: югары уку йортлары өчен дәреслек- Казан: Мәгариф, 2001.